МӨМКИНЛЕКЛӘРЕ ЧИКСЕЗ

Бернигә дә карамастан, алар – чемпионнар

> 3

ХӘРБИ ИДЕАЛ

Суворов фамилиясе Казан өчен дә ят түгел

> 3

ГАБДЕЛӘХӘТЛӘР БУЫНЫ

Тарихи хәтер өзелсә, ни булыр?

> 5

БЕРГӘ ҖЫЕЛГАНДА

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 179 (28952) | Шимбә | 3 декабрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Зөһрә САДЫЙКОВА

Авыл хуҗалыгы

Илдар Мөхәммәтҗанов

УРТАК КАЗАН

КООПЕРАТИВЛАРГА БЕРЛӘШҮНЕҢ ӨСТЕНЛЕГЕ НИДӘ?

Соңгы берничә елда авыл хуҗалыгы кооперативлары яңа көч белән эшли башлады. Аерылганны – аю, бүленгәнне бүре ашар. Эштә генә түгел, ашта да шушы кагыйдәне истән чыгармаганнар уңышка ирешә бүген. Көчнең бердәмлектә икәненә төшенеп, эш уңышлары сөендергәннәр белән аралаштык.

Уңышлы юл

Кайбыч районының Чүти авылында урнашкан «Йолдыз» кооперативы пайчылар саны буенча республикада иң эреләрдән санала. 2018 елда эшли башлаган оешмада 295 пайчы берләшкән. Араларында биш фермер һәм 200дән артык шәхси хуҗалык бар. «Йолдыз» кооперативы сөт җыю һәм ит эшкәртү белән шөгыльләнә. Ул 18 авылдан сөт җыя. Ә бу – ярты район дигән сүз. Халыктан җыелган сөтне модульле заводта суытып, Кайбычтагы җыю пунктына илтеп тапшыралар. Грант акчасына алынган ит эшкәртү буенча модульле заводта колбаса, каз, үрдәк ыслыйлар, пилмән, кәтлит, мантый, тулма (голубцы), берничә төрле тутырма һәм башка ярымфабрикатлар ясыйлар. Халык аеруча кулдан бөккән пилмән, кәтлитне, ысланган итне яратып ала икән. Иң мөһиме – ризыкларның барысы да хәләл. Колбасаны 80 процент – ат, 20 процент тана итеннән ясыйлар. Җитештерелгән продукцияне ярминкәләрдә, Апас, Кайбыч кибетләрендә саталар. Тәмле һәм хәләл ризыкларны Казан белән Чувашия Республикасына да алып китәләр.

– Кооперативның төбенә төшеп, барлык мөмкинлекләрен файдаланып эшләгән очракта, ул бик отышлы, – ди кооперативның технологы Гөлназ Щукина. – Кызганыч, безгә бар нечкәлекләрен аңлатып бирүче белгечләр җитми. Бер урында гына таптанып торасыбыз килми, алга таба барыр идек. Шушы яки киләсе елда тушенка эшли башлап булмасмы, дип тырышабыз. Аңа ихтыяҗ барлыгы сизелә.

Аның сүзләренчә, кооперативка кергән кешеләрнең мал чалдыру, ит урнаштыру белән проблемалары юк. Анысы исә үзе теләгән, кыйммәтрәк бәядән алына.

– Без тагын да ныграк үсеш алган булыр идек. Ләкин дөнья хәлләре безнең эшчәнлектә дә эзсез узмый. Башта пандемия аяк чалды, хәзер халык хәрби операция дип борчыла. Кешедә тамак кайгысы кимеде һәм бу яхшы ук сизелә. Узган ел, мәсәлән, бу вакытта продукцияне әзерләп өлгертеп булмый, сорау зур иде. Быел андый ихтыяҗ юк. Ләкин бер башлаган эшне ташлап булмый. Авырлыклар булса да, барыбер эшебездән канәгатьбез, – ди Гөлназ.

Тагын бер уңышлы эшләп килүче кооператив Сабада оешкан. Бер шәхси хуҗалыкны, ун фермерны һәм ун эре хуҗалыкны берләштергән «Умырзая» кооперативы эре мөгезле терлекләрне чалу, эшкәртү һәм итләтә сату белән шөгыльләнә. Быелның тугыз аенда оешма 512,5 млн сум табыш алган. Киләсе елда ярымфабрикатлар (пилмән, тулма, манты һәм кәтлит) әзерләмәкче булалар. Кооператив 40 кешене эшле дә, ашлы да иткән.

– Безнең кооператив электән үк эшләгән һәм аның кечкенә генә кибете булган. Мин бирегә 2015 елда килдем. 2017 елда грант алып, мал чалу цехы төзедек. Ныклап торып эшли башлавыбыз шул елга туры килә. Пайчыларның һәм кооперативка кермәүче кешеләрнең итләрен 5–6 сумга кыйммәтрәк бәядән алып, аларны сөяк белән яки аннан аерып сатабыз. Аларны үзебезнең һәм күрше-тирә районнарга, Казанга һәм Мәскәүгә ташыйбыз, – диде кооператив рәисе Рамил Гарипов.

Димәк, төп өстенлекнең берсе югары бәя булса, икенчесе – чималны урнаштырудагы уңайлылык.

– Авылның киләчәген кооперативларда күрәм, – ди ул. – Тик аның өчен дәүләтнең тагын да зуррак ярдәме кирәк.

Теркәлү генә җитми

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының авыл кооперацияләре үсеше бүлеге белгече Таһир Гомәров китергән мәгълүматлар буенча, республикада 321 кооператив теркәлгән. Бүген шуларның 156сы үз эшчәнлеген алып бара. Аларда торган пайчылар саны сигез меңнән артып киткән. Саннардан күренгәнчә, теркәлүчеләр белән эшләүчеләр арасында аерма шактый зур. Моның сәбәбе нидә соң?

– Бүген эшләрен алып бармаучылар арасында совет заманында ук теркәлгән оешмалар күп. Аларның шактые 1990 нчы елларда теркәлгән, ә аннан соң исәптән төшмәгәннәр. Бүген министрлык шундый оешмаларны ачыклап, тәртипкә китерү белән шөгыльләнә, – диде Таһир Гомәров.

Дөрес, араларында соңгы елларда гына теркәлеп, эшләрен туктатучылар, эшләп китә алмаучылар да бар. Шулай да, белгеч фикеренчә, андыйларның саны күп дип әйтеп булмый.

– Оешкан кооперативлар күпчелек очракта финанс авырлыгы кичерү, пайчыларның оешмага ышанмаулары аркасында эшләп китә алмый. Кемдер шәһәргә күченә, кайдадыр авылда терлек асраучылар кими, авыл картая. Нәтиҗәдә кооператив та эшчәнлеген алып бара алмый башлый, – дип аңлатты моның сәбәпләрен ул.

Ахыры 5 нче биттә >

Торак бәясе кими

Казан ноябрьдә икенчел торак базарында бәяләр иң нык төшкән 10 шәһәр исәбенә эләккән. Беренче өч урында – Севастополь, Мәскәү һәм Калининград.

РБК хәбәренә караганда, көзнең соңгы аенда Татарстан башкаласында 1 «квадрат» хакы уртача 142411 сум тәшкил иткән. Узган елның ноябре белән чагыштырганда 1,43 процентка кимрәк бу. Фатирлар Чаллыда да арзанайган. Бирелә 1 квадрат метр торак мәйданы бәясе – 83153 сум (2021 елның шушы аендагы белән чагыштырганда 0,85 процентка азрак).

Мәскәүдә исә ноябрьдә 1 квадрат метр, узган елның шушы чорындагыга караганда 4,24 процентка арзанаеп, 283061 сум булган.

Хезмәт хакына кадәр

Татарстанда октябрь аенда барлыгы 77729 микрозайм бирелгән. Бу – алдагы айдагыга караганда 0,7 процентка кимрәк.

Илкүләм кредит тарифлары бюросы мәгълүматларына караганда, республика «хезмәт хакына кадәр» кредит бирү буенча Россиянең 30 лидер-төбәге арасында алтынчы урынны били. Октябрь йомгаклары буенча, 5 төбәк исемлегенә Мәскәү (140222 займ), Мәскәү өлкәсе (120674), Краснодар крае (96717), Свердловск өлкәсе (92946) һәм Башкортстан (88549) кергән.

Гомумән, бу айда Россиядә җәмгысы 2,63 миллион микрозайм бирелгән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, аларның саны 0,8 процентка азайган.

Шул ук вакытта быел сентябрь аенда Татарстанда микрозаймның уртача күләме август аендагыга караганда 3 процентка артып, 9652 сумга җиткән.

Алтын бизгәге

Россиядә, быел тиешле кызыксындыру чаралары күрелгәннән соң, халыкта алтын сатып алуга ихтыяҗ 10 тапкыр арткан. Бу хакта ТАСС хәбәр итә. «Алтын «оекта»гы долларларны алыштырырга тиеш», – дигән финанс министры урынбасары Алексей Моисеев Федерация Советындагы еллык киңәшмәдә.

Исегезгә төшерәбез: 9 мартта Россия Президенты Владимир Путин банклардан кыйммәтле металл сатып алуга салымнан азат итү турында законга кул куйды. Шуннан соң ул банкларга чит ил акчасына да алтын коелмалар сатуны рөхсәт иткән законны имзалады.

Тайгак юлда сак бул!

Татарстанның травматология бүлекләрендә, бозлавык сәбәпле, «урак өсте» башланган. «Реальное время» мәгълүматлары буенча, бер бүлек һәр көн саен 20гә якын кешене кабул итә.

Табиблар әйтүенчә, кышын тайгак юлларда бигрәк тә хатын-кызлар еш имгәнә. Ир-атлар «дөресрәк» егылу нәтиҗәсендә, күпчелек очракта бәладән котылып кала. Шул ук вакытта 50дән яшьрәк ханымнар, егылганда, кулларына таянып калырга тырыша. Шуңа күрә алар арасында беләзек, терсәк сөяген сындыручылар күп. Өлкәнрәк яшьтәге хатын-кызларда бот сөяген сындыру куркынычы зур, ә ир-атларның күкрәк читлеген имгәтү очраклары еш теркәлә.

Белгечләр киңәш иткәнчә, егылганда, ян белән төшәргә тырышыгыз. Ә инде артка таба киткәндә, башны ничек тә күтәреп калыгыз.

Инвалидлар yнкөнлеге

Бер җылы сүз җитә

Алар берәүдән дә ким түгел! Үзләренә булган игътибардан да күңелләре тула күбесенең. Әллә ни күп тә эшлисе түгел: кайчак ишек ачарга булышсак, урам аша чыкканда ярдәм итсәк, юл күрсәтсәк, шул җитә дә кебек.

Татарстанда физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә ярдәм күрсәтү өчен быел федераль бюджеттан – 2,7 млрд, республика казнасыннан 47,7 млн сум акча тотылган. Республикада 268 мең физик мөмкинлеге чикләнгән кеше яши. Шуның 17 меңе – балалар.

– Безнең бурыч – бу кешеләргә җәмгыятьтә үз урыннарын табып, җайлашып яшәргә, үзләренең мөмкинлекләрен тормышка ашырырга ярдәм итү. Шуңа күрә тернәкләндерү социаль сәясәтнең төп юнәләше булып тора, – диде Татарстанның хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльмира Зарипова «Татар-информ»да узган очрашуда . – Хәзерге вакытта республикада инвалидлар өчен 27 тернәкләндерү үзәге бар. Аларның 19ы – балалар, 8е өлкәннәр өчен эшли. Узган ел бу үзәкләрдә 6,6 мең өлкән кеше һәм сәламәтлекләре чикләнгән 11,6 мең бала дәваланды.

Эльмира Зарипова, сабыйларның авыруларын кечкенәдән үк ачыкларга кирәк, ди. Ник дигәндә, алдан ачыкланган чирләрне дәвалау нәтиҗәлерәк. Вакытында табибка күренеп, тиешле чарасын күрүчеләр арасында сәламәт тормыш рәвешенә кайтучылар да бар икән.

– Яңа социаль технологияләр кертү инвалидларны тернәкләндерүнең аерылгысыз өлешенә әйләнде. Иппотерапия, кинезотерапия, Монтессориның коррекцион педагогика алымы һәм начар ишетүче балалар өчен Леонгард ысулы балалар өчен тернәкләндерү үзәкләре эшчәнлегенә кертелде. Мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә карата социаль сәясәтнең төп юнәлеше профилактика чаралары булырга тиеш. Бу максаттан республикада 2019 елдан башлап алдан ярдәм күрсәтү системасы оештырылды. Узган ел мондый ярдәм 4,7 мең балага күрсәтелгән булса, 2022 елда 4,5 мең бала медицина тикшеренүе узган.

Олырак балаларны дәвалауда кыенлыклар да бар. Авыру бала үстерүче әниләр дәүләт тернәкләнү үзәкләренә елга ике мәртәбә генә барып булганын әйтә. Бушлай үзәкләрдә 21 көн генә торып була. Тагын да дәвалауларын телисең икән, акча түләргә кирәк. Әти-әниләр моңа риза түгел. Тик башка чаралары да юк. Алар йә кешедән ярдәм сорап, йә үзләре акча табып, сабыйларының сәламәтлеген кайгырта. Министр да елга ике мәртәбә генә дәваланып калмаска, күнегүләрне өйдә дәвам итәргә киңәш итә. «Без теләге булган әти-әниләрне махсус курсларда укытып та чыгарабыз», – ди ул.

Быел 5 меңнән артык әти-әни баласына ярдәм итәр өчен өстәмә белем алган. Алар арасында Балтачта яшәүче Рәзилә Мәхмүтова да бар.

– Елына ике тапкыр дәваланып кайту гына җитми. Күп кенә тернәкләндерү үзәкләрендә булырга туры килде. Мин, табиблардан рөхсәт алып, кызымны дәвалауларын карап тора идем. Нинди күнегүләр эшләтәсе, массажны ничек ясыйсы. Барысын да өйрәндем. Өйгә кайткач, бер көн тик утырмадык. Кеше эшкә йөргән кебек, без үз бүлмәбезгә кереп бикләнә идек. Баламның һәр күзәнәгенә барып җитәрлек итеп сәгатьләр буе күнегүләр ясадым. Безгә логопед ярдәме дә кирәк булды. Үзебездә андый белгеч булмагач, укып кайттым. Хәзер балам белән үзем шөгыльләнәм, – ди Рәзилә. – Кыенлыклар да очрап тора. Кайчак зур шәһәрләрдә дә арба белән кереп булмый торган җирләр бар.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Александр ДВОЙНЫХ, Федерация Советының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек сәясәте, казылма байлыклардан файдалану комитеты җитәкчесе:

Күпбалалы гаиләләргә үз йортларын төзү өчен процентсыз ипотека бирү турында сөйләшә башларга вакыт җитте. Илдә демографик хәлне яхшыртырга телибез икән, ишле гаиләләргә бушка коры җир кишәрлеге бирү генә аз, алар биредә йорт төзесен өчен, кызыксындыру чаралары кирәк. Шундыйларның берсе – процентсыз ипотека.

(«Парламентская газета»дан)

АКЧАНЫ КАЯ КУЯСЫ?

НАФИ аналитика үзәге белгечләре Россия халкыннан: «Акчаны ничек сакларга?» – дип сорашкан. Статистика күрсәткәнчә, елларына күрә халыкның бу җәһәттән фикере дә үзгәргән.

Милек сатып алу
2020 ел >> 39%
2022 ел >> 42%

Алтын сатып алу
2020 ел >> 18%
2022 ел >> 24%

Сумнарда саклау
2020 ел >> 10%
2022 ел >> 16%

Валюта сатып алу
2020 ел >> 10%
2022 ел >> 6%

Сөенечле хәбәр!

2022 елның 5–15 декабрь көннәрендә «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән язылып була!

П2435 жомга саны
Ташламалы бәя
444 сум 54 тиен
гадәти бәясе – ~~512 сум 70 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга
Ташламалы бәя
980 сум 10 тиен
гадәти бәясе – ~~1143 сум 96 тиен~~

Реклама 16+

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Кеше, әтәч һәм матриархат

Адәми зат киемен генә алыштыра. Эче аның үзгәрми. Дөресрәге, ифрат та акрын үзгәрә. Яхшы якны күздә тотып әйтүем. Бик акрын яхшылана кеше. Меңәр елдан торган чорлар, дәверләр үтә, кешедәге кием генә икенчеләнә. Борыңгы чорларда бил, билдән аскы тирәне каплаучы тире кисәге кигәннәр, Рим империясе заманнарында тога дигән тукымага уранганнар, соңрак камзул, фраклар киткән. Хәзер джинсы яраталар. Кеше затының эче, зурдан алганда, элекке. «Homo sapiens»ның күпчелегендә моннан мең, ике мең ел элек тә булган кимчелекләр. Ул һаман да шуларга буйсынып яши. Мин-минлеккә, шөһрәт, дан сөюгә, өстенлеккә, шул ук туемсызлыкка. Киләчәктә дә дөнья белән шул затсыз сыйфатлар идарә итмәячәк, дип әйтеп булмый, итәчәк.

Бүген технологияләр, алар китергән уңайлыклар бар булган чик, чаманы узды, алардан без күккә ашкан манара төзеп куйдык. Әхлак, кешелеклелек дигән корылма аның янында мескен бер түмгәк кенә. Бу хәл безне – кешеләр киләчәгенең күрәчәк фаҗигаләрнең алшарты түгелме? Хәер, без аларны әле дә күзәтәбез. Фәнне, техниканы ирләп, адәми зат йөз, мең төрле корал системалары тудырды. Гади кораллардан алып, карыбына атом бомбасы куелган гипертавышлы ракетага кадәрле – барысы да кеше үзе кебекләрне үтерергә хәстәрләнгән нәрсәләр. Кеше дигән җан иясенең асылында күпме вәхшилек! Әле яңа гына укыдым, япон язучысы бөтендөнья сугышларын «Беренче Бөтендөнья күмәк үтереш», «Икенче күмәк үтереш» дип атарга тәкъдим итә. Ул хаклы түгел, дип кем әйтә ала?

Технологияләр тудыргандары турында да онытмыйк. Җир, табигать, бездән соң киләчәк буыннар турында, иминлек турында искәрмәдек. Кирәген дә, кирәкмәгәнен дә ясап тордык. Елдан-ел күбрәк углеводородлар ягу сәбәпле, Җирдәге уртача температура күтәрелә, климат үзгәрә. Тик галимнәрдән башка моңа беркемнең дә исе китми. Әлегә яшәрлек бит. Дәүләтләр, дәүләт җитәкчеләренең эше каты – алар дөньяга сыеша алмыйча, җир бүлешә, кемдә күбрәк мин-минлек, кем күбрәк үзсүзле – шуны ачыклый, тукыш оештыра. Планетада тынычлык юк. Һәркем каршы якка үзенең гаярьрәк, гайратлерәк икәнен исбатларга алынган.

Гайрәтлерәк дигәннән. Балачактагы бер күренеш истән чыкмый. Күршеләрнең таң атса-атмаса да кычкырырга яраткан олы кызыл әтәче ни хикмәт беләндер нейтраль территория – урамда безнең гәүдәгә бераз кайтышрак ак әтәч белән маңгай-маңгай очрашты. Мондый очрашуның ни белән беткәнен авыл баласына аңлатып тормасаң да була. Шул тирәдә уйнап йөргән без – бала-чага исенә килгәнче, тирә-якка аклы, кызыллы каурыйлар оча башлаган иде инде. Без авыз ачып тамаша кылабыз, алар ярсып бер-берсенә ябырыла, тилереп чукый. Кан тапларны күрше әтәченең кызыл кикеменә бик шәйләнмәсә дә, безнең сугыш чукмарының ак каурые ярыйсы чуарланды. Күрше абый сапы себерке белән селтәнеп, икесен ике якка куып җибәрмәсә, валлаһи, үлгәнче сугышалар иде.

Әтәчләр сугышыр да. Барысы да – табигатьтән. Миллион еллар барган эволюция ата җан ияләрен, кошмы ул, җанвармы, шулай бергә-бер көч сынаштыра. Бары көчлененең генә нәсел калдырырга хокукы бар. Башкача биологик төр зәгыйфьләнә, юкка чыгарга мөмкин. «Альфа-самец» кына нәсел калдыра, көтү, өер белән яшәгәннәр арасында ул әле тагын – өер башлыгы да. Ул – иң гайрәтлесе, иң усалы, кирәк булса, иң рәхимсезе дә. Кыргый табигатьтә башкача була алмый. Табигатьтә һәммә нәрсә камил, эволюция андагы бар җан иясенә дә үз урынын, холкын биргән, һәрберсен үз киштәсенә урнаштырган. Бүредә агрессия бар, ул – ерткыч. Тик ул бер куянны тотып ашаса, икенчесе артыннан чапмый. Бер урманның мең бүресе бергә җыелып, икенче урманның мең бүресенә каршы яу да чапмый. Ерткычның бердәнбер коралы – тешләре. Алар мылтык тота яисә танк иярли дә алмый. Ягъни «Бүреләр – ул кадәр үк ерткыч түгелләр».

Кыргыйлыктан котылган, үзен аңлы санаган зат – «homo sapiens»та исә, технологияләр сәбәпле, ерткычлык күпкә «продвинутый»рак. Бу җәһәттә гади халыкка артык бәйләнеп булмаганда да, «өер башлыклары»н аклау кыен. Югары җитәкчеләрнең хәтсезенә ипи ашатмасаң – ашатма, кәнәфи, доминантлык, өстенлек бир. Алар – шул ук «альфа-самец»лар. Аларның каннары тулы тестостерон. Пушкин әкиятендәге балыкчы карчыгының «владычица морей» буласы килгән кебек. Һәм... Кыргый табигый турнир – әтәч сугышы урынына масштаблы бәрелеш, канкоеш ярала. Мин-минлекле лидерның үзенә каурый очырасы юк бит. Аның баштанаяк коралланган армиясе, буйсынучан халкы бар.

Вацлав Гавел кебек язучы, фикер иясенең президентлыгы яисә Марк Аврелий кебек философның императорлыгы – үтә дә сирәк күренеш. Тарихи хата. Ә бит андый «хаталану» күбрәк булганда Җир йөзендә гаделсезлек, сугышлар азрак булыр иде. Чөнки «ботан» Президент кәнәфиендә дә «ботан» булып кала, аның табигате шундый, аның әтәч буласы, кем беләндер көч аша мөнәсәбәт ачыклыйсы килми. Аңарда агрессия юк. Фикерле зат гомумән аның ишедән югары тора. Тик, ни кызганыч, андыйларны җитәкче булу, доминантлык аз гына да кызыктырмый...

Кыргый табигатьтән аерылган кеше кыргыйлыктан котылмады, илаһи зат булып җитешмәде. Кеше затына зиһен биреп табигать бәлки ялгышкандыр? Бәлки зиһен дигәнебез кирәкмәгән мутация, табигать-ананың ялгышыдыр. Кеше бит акыллы түгел. Ул бары акыллы булырга сәләтле генә. Аерым шартлар булганда. Күрәмсең, Җирдә андый шартлар әлегә җитенкерәми. Шуңа да яшәешебезнең атасы-анасы юк безнең. Бәндә акыллы булса, миллионнар дуамал «альфа-самец»ларга буйсынмас, үзләреннән бау иштермәс иде...

Тик бәлаләрдән котылуның бер юлы бар кебек. Властьны бөтен тарафларда да хатын-кызга биреп. Барлык илләрдә дә «Ир затлары дәүләт идарәсенә катнаштырылмый» дигән закон кабул итеп. Сезнең кайчан да булса тузан туздырып, каурый очырып, ике тавыкның сугышканын күргәнегез бармы? Юк, күрмәячәксез дә! Дуракмыни алар сугышырга! Аларның әле нәсел калдыру җәһәтеннән йомырка саласы, чеби чыгарасы бар. Сугышып көч, энергия әрәм иткәч, йомырка каян булсын? Хатын-кыз ул – беренче чиратта ана. Бер ана да баласын яу кырында ятып калсын дип үстерми. Бәс шулай икән, матриархатка кайтуга ук без сугыш дигән гарасатны бөтенләй онытачакбыз. Ирләрне хакимиятләрдән иртәгә үк куа башлыйбызмы?

КУНАКЧЫЛЛЫК КЫНА БӘЙЛӘМИ

Көнчыгышка йөз тотып. Татарстан Президентының бу юнәлештә эш сәфәрләре дәвам итә. Бу көннәрдә республика җитәкчесе Үзбәкстанда иде. Хезмәттәшлек юлларын барлау белән бер рәттән, ул Сәмәркандта уза торган бизнес-форумның пленар утырышында чыгыш ясады.

tatarstan.ru

Мәгълүм булганча, чарада ике илнең хөкүмәт башлыклары – Михаил Мишустин һәм Абдулла Арипов катнашты.

Форумның модераторы буларак чыгыш ясаучы Россиянең икътисади үсеш министры Максим Решетников Татарстанны Үзбәкстан белән актив хезмәттәшлек итүче төбәкләрнең берсе буларак тәкъдим итте һәм республика Президентыннан әлеге уңышлы тәҗрибә турында сөйләвен сорады.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов сүзләренчә, быел Үзбәкстан белән ике арада уртак проектлар чынга ашырылды. Болар – «Чирчик» химик-индустриаль технопарк ачылышы һәм Джизак шәһәрендә КФУ филиалын ачу. Моннан тыш башка зур предприятиеләр дә хезмәттәшлек мөмкинлекләрен үстерә.

Узган елгы нәтиҗәләргә күз салсак, Татарстан белән Үзбәкстан арасында товар әйләнеше 193 млн доллардан артып киткән. «Бу елның 9 аенда без товар әйләнешенең 47 процентка үсүен күзәтәбез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Моннан тыш, Татарстан Президенты искәрткәнчә, гуманитар хезмәттәшлек өлкәсендә дә эшләү мөһим. Әйтик, бүген Татарстан вузларында Үзбәкстаннан 3335 кеше белем ала. Ике якта да ике халыкның диаспоралары бар. Сүз уңаеннан, Рөстәм Миңнеханов Үзбәкстан җитәкчелегенә җирле татар җәмәгатьчелегенә ярдәм итеп торуы өчен рәхмәтен дә әйтте.

Моннан тыш эшлекле форумда туризм өлкәсе турында да сүз булды. Максим Решетников әйтүенчә, 2022 елда Россия халкының Үзбәкстанга туристик сәфәрләре арткан. Беренче яртыеллыкта республикада 126 мең кеше кунак булган. Бу элегрәк булган күрсәткечтән ике мәртәбә күбрәк.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, туризм тармагына Татарстан да аерым игътибар бирә. «Без яңа туристик проектлар системасын булдырабыз. Ул туристларга сыйфатлы ял тәэмин итәчәк. Соңгы 9 айда Татарстанда туристлар саны 11 процентка артты», – диде Татарстан Президенты.

Президент искәрткәнчә, республиканың Үзбәкстан белән туры авиаэлемтәсе бар. Бу да туристлар агымы үсешенә йогынты ясый. «Хәләл принцибы буенча хезмәт күрсәтү системасы үсеш алган», – дип искәртте Рөстәм Миңнеханов.

Фикер

Ләйсән ХАРИСОВА,
бәйсез финанс белгече:

– Икътисадның көнчыгыш юнәлешкә борылуы берәү өчен дә сер түгел инде. Ул чит ил санкцияләре кертелүгә бәйле. Бу безгә якын-тирә партнерлар белән тыгызрак аралаша башларга бер этәргеч ясады.

Минемчә, көнчыгыш юнәлеш – яхшы юл. Татарстанны гына алыйк. Әйтик, авыл хуҗалыгы, машина төзелеше һәм нефть эшкәртү юнәлешендә хезмәттәшлек итә алабыз. Бу республикага зур мөмкинлекләр ача.

Аннан, көнчыгышны бизнес кына түгел, уртак дин дә бәйли бит. Бер төрле диндәге илләр берләшкәндә җиңелрәк.

Шуны да әйтергә кирәк: бу хезмәттәшлек, дуслык җепләрен булдыру бүген генә килеп чыккан күренеш түгел. Моңа кадәр дә булган ул. Әмма күләме аның кадәр булмаган. Мөнәсәбәтләрне җайга салу икътисадка яхшы тәэсир итә. Хәзер авыр вакытлар. Дуслык җепләре ныгыса, мәсәлән, бу илләр аша ниндидер товарлар кертү мөмкинлеге дә булыр иде. Чикләүләр безне йомылырга, бәләкәй ояга кертеп утыртырга мөмкин иде. Әмма безнең республика Президенты чикләрне киңәйтергә тырыша. Бер-береңә ярдәмләшеп яшәсәң, ике як та зур файда күрәчәк.

КАТЛАУЛЫ ҺӘМ ҖАВАПЛЫ

3 декабрь – Юрист көне. Бу уңайдан Татарстан юстиция министры Рөстәм Заһидуллин республиканың барлык юристларын һәм ветераннарны һөнәри бәйрәмнәре уңаеннан котлады.

«Юрист һөнәре катлаулы һәм җаваплы, – диелә котлауда. – Бүген тормышның бер генә өлкәсе дә хокукый ярдәмнән башка яши алмый. Юристлар кешеләрнең хокуклары-ирекләрен яклау-саклауда мөһим роль уйный. Халыкның тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыру, законнарны тел-теш тидергесез үтәү башлыча аларның эшенә бәйле.

Юристларның югары дәрәҗәдәге профессионализмы, намуслы хезмәте, максатка омтылышлылыгы алга таба да республика халкының иминлеге нигезе булып торачагына ышанам. Нык саулык-сәламәтлек, бәхет һәм һөнәри бурычларны үтәүдә уңышлар, яңа үрләр телим!»

ЕРАКТАГЫНЫ ЯКЫН ИТӘСЕ

Бер йодрыкка берләшер чак. Татарстан Президенты каршындагы Ватандашлар эше буенча Координация советы утырышында иң еш телгә алынган фикер шушы булды. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренә караганда, чит илләрдә яшәүче ватандашлар белән аралашу Россия Тышкы эшләр министрлыгы белән бергә оештырыла.

– Тулаем алганда, бу эштә федераль дәрәҗәдә зуррак игътибар бирелә башлады, – диде Фәрит Мөхәммәтшин, ил күләмендә уздырылган чараларны искә алып. – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, графигы никадәр генә тыгыз булса да, читтә яшәүче ватандашлар белән очрашырга җай таба. Быел ул Казахстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстан, Төркия һәм Азәрбайҗанда яшәүче татарлар белән күреште. Парламент башлыгы Ислам хезмәттәшлеге оешмасына (ИХО) кергән дәүләтләр белән мөнәсәбәтләргә аерым тукталды. Казанның быел ИХОның яшьләр башкаласы булуы яшьләрне җәлеп итүгә яңа мөмкинлекләр ачты. Моннан тыш, Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан уздырылган чаралар да ватандашлар белән араларны якынайтырга мөмкинлек бирә.

Фәрит Мөхәммәтшин узган ел илдә халык санын алу оештырылганын да искә алды. «Безнең төп бурыч татарлар санын саклап калу, туган телебезне, гореф-гадәтләрне алга таба үстерү. Бүгенге катлаулы шартларда ватандашлар белән мөнәсәбәтләрнең әһәмияте тагын да арта. Бүген алар безнең игътибарга аеруча мохтаҗ», – диде ул.

Фәрит Мөхәммәтшин килеп туган вазгыятьтә ватандашлар белән икътисади мөнәсәбәтләрне ныгытуга да зур игътибар бирергә кирәклеген искәртте.

– Безнең эшчәнлеккә бәйле булмаган кыенлыклар килеп туута карамастан, Татарстан икътисади яктан узып баручы елны уңышлы йомгаклый. Республикага зур игътибар бирелде. Бу аңлашыла да. Без бик көчле, икътисадыбыз да күптармаклы. Нефтебез бар, машинасын да, очкычын да ясыйбыз. Быел рекордлы күләмдә уңыш җыеп алдык. Күпмилләтле халкыбызның тырыш хезмәт нәтиҗәсе бу. Бу – безнең өстенлегебез. Без аны ватандашлар белән мөнәсәбәтләрдә дә өлге итәргә тиеш, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев сүзләренә караганда, бүген конгресс дөньяның 45 илендә яшәүче татарларны берләштерү юнәлешендә зур эш алып бара. Зур вакыйгалар дип ул Донецк, Луганск республикаларында да мөфтиятләр барлыкка килүне, Перу белән Таиландта беренче тапкыр милли бәйрәмебез – Сабантуй уздырылуны атады.

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең пиротехник һәм композицион материаллар эшләнмәләре технологияләре кафедрасы мөдире **Бурдикова** Татьяна Владимировнага **«Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Лаеш район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы – баш ветеринария табибы **Портнов** Олег Васильевичка, «САРМАН» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең зоология ветеринария хезмәте өлкән ветеринария табибы (Татарстан Республикасының Сарман районы) **Салихҗанов** Җәүдәт Әсгать улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Таң» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчысы (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Идрисов** Нияз Риф улына, «Союз-Агро» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тракторчы-машинисты **Каретников** Сергей Анатольевичка, «Татарстан» авыл хуҗалыгы предприятиесе җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Шакирҗанов** Җәмил Камил улына **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы механизаторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Горький тимер юлында тимерюлчылар һәм транспорт төзүчеләре Россия һөнәр берлегенең Юл территориаль оешмасы рәисе урынбасары – Ижевск төбәге структур бүлекчәсе җитәкчесе **Әхмәтзакирова** Лилия Рәшит кызына, Актаныш муниципаль районының «Актаныш автотранспорт хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе автобус йөртүчесе **Бәшәров** Роберт Альберт улына, «Түбән Каманың 1 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» акционер җәмгыяте автомобиль йөртүчесе **Назаров** Александр Николаевичка, «Чаллы-Бройлер» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе **Насыйров** Фарса Мирзасалих улына, «Россия тимер юллары» ачык акционер җәмгыяте филиалы – Хәрәкәт белән идарә итү үзәк дирекциясе структур бүлекчәсе – Хәрәкәт белән идарә итү Горький дирекциясе структур бүлекчәсе – Әгерҗе тимер юл станциясе буенча дежурные **Бочилова** Галина Александровнага, «Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы – Хәрәкәт белән идарә итү үзәк дирекциясе структур бүлекчәсе – Хәрәкәт белән идарә итү Горький дирекциясе структур бүлекчәсе – Әгерҗе тимер юл станциясе буенча дежурные **Шевелева** Светлана Петровнага **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Бер җылы сүз җитә

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Министр да «Уңайлы мохит» программасына тукталды. 2011–2020 елларда Татарстанда 921 мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль яклау, мәдәният, физик культура һәм спорт объектлары физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр өчен җайлаштырылган. Бу программа чараларын үтәүгә 2,7 млрд сум чамасы акча тотылган.

Физик мөмкинлеге чикләнгән өлкәннәр дә читтә калмый. Кирәк кешеләр өчен сиделка хезмәте күрсәтелә. Аларны караучы якыннарын бушка укытып кайтаралар. Эшләүче инвалидларга дәүләттән ярдәм чаралары каралган. Әйтик, үз эшен башларга теләүчеләргә 145 мең сум күләмендә акча бирелә.

Очрашуда инвалидларга тиешле тернәкләндерү чаралары һәм ял йортына юлламалар турында да сөйләштеләр. Инде хәбәр иткәнебезчә, 1 июльдән физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләр үзенә кирәк-яракны, коляска, аяк киеме, тернәкләндерү чарасын электрон сертификат ярдәмендә ала. Россия Социаль иминият фондының Татарстан буенча бүлеге идарәчесе Фердинант Закиров сүзләренчә, быел бу сертификатны 941 кеше алган. Ул шәхси тернәкләндерү программаларыннан чыгып бирелә.

Республикада физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә игътибар зур. Сабыйлар өчен бакчалар эшли, укучылар өчен махсус мәктәпләр бар. Хәтта авыру бала үстерүче әниләргә 3–4 сәгатькә балаларын калдырып тору өчен махсус үзәкләр дә ачылган. Әлегә алар күп түгел, ә менә сабыен калдырып, үз йомышларын хәл итәргә, бераз гына ял итәргә теләүче әниләр күп икән. Казанда урнашкан үзәккә инде киләсе елның апрель аена кадәр буш урыннар юк.

3 декабрьдә бөтен дөнья җәмәгатьчелеге Халыкара инвалидлар көнен билгеләп үтә. Бу уңайдан Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры Эльвира Зарипова мөрәҗәгать юллады.

«Бу мөһим дата – бәйрәм түгел. Бу – мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең интеграцияләнүенә кагылышлы мөһим сорауларны чишү өчен берләшүгә сәбәп. Татарстанда махсус ихтыяҗлары булган кешеләр өчен күп эш эшләнде һәм эшләнә, ләкин республикабыз мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр өчен барлык кирәкле шартлар тудырылган һәм шәфкатьлелек хөкем сөргән толерантлык территориясенә әверелүе өчен тагын да күбрәк эшләргә кирәк. Бу истәлекле көндә барыгызга да сәламәтлек, күңел күтәренкелеге һәм көч-куәт телим! Без бергә. Без бер-беребезгә һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер», – диелгән мөрәҗәгатьтә.

ШАУЛАСЫН ГЫНА!

Кискән һәр агач урынына яңасы утыртылсын. Татарстан урманчыларына шундый бурыч куела. Урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров әйтүенчә, күрсәткечләрне 2024 елда тигезләргә ниятлиләр: кискән һәм утыртылган агачларның саны бер булачак. Журналистлар белән очрашуда орлык әзерләү, урман техникалары сатып алу, янгынга каршы тору турында да сөйләштеләр.

Министр аңлатуынча, урман хуҗалыгындагы бар эшләр дә «Экология» илкүләм проектының «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проекты буенча башкарыла.

– Быел федераль бюджеттан 111 миллион 500 мең сум акча бүлеп бирелде. Шуның 89 миллион 500 меңе урман утырту эшләренә тотылды, 22 миллион сумга урман техникасы алдык. 3 мең 619 гектарда урман утыртылды. Агачларның черегән, корыганнары ел саен яңартылып тора, – диде министр. Сүз уңаеннан, 2023 ел өчен «Урманнарны саклау» төбәк проектына 96 миллион 200 мең сум акча бирелә.

Быелга орлык әзерләү тәмамланган. Урманчылар агач орлыкларын җыеп, аларны питомникларда үстерә. Шунысы да бар: быел имән чикләвеге аз булган. Аның каравы ылыслы һәм яфраклы агач орлыкларын күп итеп хәстәрләгәннәр. Җыйдың да бетте түгел. Иң элек ул орлыклар әллә ничә кат тикшерү уза икән. Белгечләр аларның гөмбәчекләр белән зарарлану-зарарланмавын тикшерә. Орлык сыйфатлы икән, аңа махсус сертификат бирелә. Шул рәвешле быел 11 мең 460 килограмм орлык әзерләнгән. Министр бу эштә иң тырышлар арасында Нурлат, Саба, Арча, Мамадыш урманчылыкларын телгә алды.

– Кәлшәләрне республикада эшләүче 51 питомникта әзерлибез. Шулай ук Саба селекция-орлыкчылык үзәгендә елына 12 миллион данә ябык тамырлы үсентеләр җитештерелә, – ди министр. – Быел 33 миллион 950 мең данә үсенте әзерләдек. Аларның 25 миллионнан артыгы – ылыслы, 7 миллионы – яфраклы агачлар, 500 меңе – куак.

Утырткан агач утта әрәм булмасын өчен, урманчылар яз-җәй айларында аеруча җиң сызганып эшли. Көннәр кызу торганда алар тәүлек буе уяу тора. Урманнарны күктән дә күзәтәләр. Министр быел урманнар өстеннән 52 тапкыр самолетта очуларын әйтте.

– Җәяү дә йөрибез. Янгын куркынычы югары булган вакытта 18,2 мең тапкыр патрульгә чыктык. Иң авыры – июль-август айларындагы эсселек, – диде министр. – Шунысы сөендерә: быел урман янгыннары күзәтелмәде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

МАРИНА ФИЛИППОВА:

«ВОЛОНТЕРЛЫК ЯҢА ТОРМЫШ БАШЛАРГА ЯРДӘМ ИТТЕ»

Байтак вакыт яман шешкә каршы көрәшеп, ахыр чиктә аны җиңә алган Марина Филипповага янәдән яши башларга башкаларга игелек кылу ярдәм итә. Бүген ул – «көмеш» волонтерларны берләштерә торган «Молоды душой» федераль программасының илчесе, «Вектор-V» проектының җитәкчесе, күп кенә дөньякүләм чараларда тәҗрибә туплаган ханым. Ә кичә генә ул «Мәрхәмәтле Татарстан» республика премиясендә «Елның «көмеш» волонтеры» исеменә лаек булды.

«Көмеш» волонтерлар (яшьләре 55тән узган волонтерлар. – **Авт.**) хәрәкәтенә 2019 елда – башкаларга игелек кылуның үзенә яңа тормыш башларга ярдәм итәчәген аңлагач кушыла ул.

– Озак кына авырудан соң, миңа инвалидлык бирделәр. Бу исә – бөтенләй яңа тормыш дигән сүз. Шушы тормышта үземне табасым килде. Хәзер инде волонтерлык – минем яшәү рәвешем, күңел халәтем, – ди Марина ханым.

Бу игелекле эшкә кушылганда, аның үзенең дә сәламәтлеге ныгып бетмәгән була. Көн дә башкаларга ярдәм итәргә чыгып чаба башлагач, якыннары бик борчыла. Әмма Марина ханымны бу эшеннән берсе дә тыймый. Улы Роман исә тота да өйләрендә «Серебро-51» дип аталучы волонтерлык корпусы ясап куя.

– Пандемия башланганда, гаиләбез белән волонтерлар булуыбыз турында беләләр иде инде. Шуңа да безгә «БезБергә» программасында катнашырга тәкъдим иттеләр. Шулай итеп, гаиләбез белән башкаларга ярдәм итәргә керештек. Көндезләрен кирәк кешегә ашамлыклар, дарулар ташыдык. Ә төннәрен мин гуманитар ярдәм сорап язучыларның гаризаларын эшкәрттем. Иртән инде ул кешеләр тиешле ярдәмне ала торган иде. Пандемия чоры безне бик сынады. Хәзер инде берни дә куркытмый. Өстәвенә безнең сафлар тагын да артты: кызымның гаиләсе дә, дусларыбызның гаиләләре дә кушылды, – дип сөйләде Марина Филиппова.

«Серебро-51» корпусының иң өлкән волонтерына 75 яшь булса, иң кечкенәсенә – 6 яшь. Марина ханымның каенанасы һәм оныгы да читтә кала алмаган. 75 яшьлек әбекәй оекбашлар, бияләйләр, мунчалалар бәйли, ә 6 яшьлек кызчык чаралар уздыруда катнаша икән.

Марина ханым волонтерлык тәҗрибәсен төрле чараларда катнашып та арттыра.

– Мин катнашкан беренче масштаблы чара – WorldSkills – 2019 чемпионаты. Дөресен генә әйткәндә, анда катнашу миңа көчле авыруым белән дә тулы көчкә яши алачагымны аңларга ярдәм итте. Шулай ук миңа EURO – 2020, FIFA – 2021 кебек дәрәҗәле чемпионатларда катнашу бәхете дә тәтеде, – ди ул.

Моннан тыш, Марина Филиппова авыр хәлле гаиләләрдә тәрбияләнә торган балалар өчен эшләүче «Вектор-V» проектын да җитәкли. Аның үзенчәлеге – шушы балаларны волонтерлык хәрәкәтенә җәлеп итеп, аларның һәркайсын махсус әзерлеге булган берәр «көмеш» волонтерга «беркетү». Ике буын волонтер чараларда да, башкаларга ярдәм иткәндә дә бергә булырга тиеш. Шул рәвешле проект психологик ярдәмгә мохтаҗ балаларга тормышта үз урыннарын табарга булышуны күз уңында тота.

– «Көмеш» волонтерларыбызның, ә бу очракта остазларның төп бурычы – ул балалар белән янәшә булып, аларның кызыксынуларын ачыклау. Кайсы юнәлеш ошый аларга? Кайсы очракта күзләре яна? Менә шуны вакытында ачыклап, дөрес юл күрсәтергә кирәк. Максатыбыз шул, – дип сөйләде Марина ханым.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Кичә Казанда «Мәрхәмәтле Татарстан – 2022» премиясенә ия булучыларның исемнәре билгеле булды. Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы «Пирамида» күңел ачу үзәгендә узды. Республиканың иң яхшы волонтерлары – түбәндә.

- Россиякүләм #МыВместе акциясе кысасында ел волонтеры – Игорь Храмов (Лениногорск).
- Гражданлык һәм патриотизм юнәлешендә ел волонтеры – Саимә Шаһиәхмәтова (Питрәч).
- Сәламәтлек саклау өлкәсендә ел волонтеры – Илнур Мөхәммәдиев (Түбән Кама).
- Мәдәният өлкәсендә ел волонтеры – Елизавета Перевощикова (Казан).
- Хайваннарга ярдәм итү өлкәсендә ел волонтеры – Люция Данилова (Лениногорск).
- Чаралар уздыру өлкәсендә ел волонтеры – Валерия Сугак (Казан).
- Социаль өлкәдә ел волонтеры – Румилә Гәрәйшина (Казан).
- Туризм өлкәсендә ел волонтеры – Алена Фәйзуллина (Казан).
- Гадәттән тыш хәлләр өлкәсендә ел волонтеры – Алена Афонина (Казан).
- Экология өлкәсендә ел волонтеры – Анна Баймяшкина (Казан).
- Елның «көмеш» волонтеры – Марина Филиппова (Казан).
- Елның яшь волонтеры – Валерия Отлетаева (Казан).
- Югары уку йорты каршындагы иң яхшы волонтерлык үзәге – Казан энергетика университетының «Энергия добра» оешмасы.
- Урта махсус белем бирү йорты каршындагы иң яхшы волонтерлык үзәге – Яшел Үзән механика көллиятенең «Пульс жизни ЗМК» оешмасы.
- Иң яхшы мәктәп волонтерлык үзәге – Иннополис лицеендагы Innoheart оешмасы.
- Волонтерлык хәрәкәтен оештыручы иң яхшы үзәк – Әлмәтнең «Мәрхәмәтле Әлмәт» оешмасы.
- «Татарстанның ел волонтеры – 2022» – Аммар Хөсәйн (Казан).

Көчле рухлылар

Чикләнмәгән мөмкинлекләр

Кемдер чүлмәк ясауда, кемдер кирпеч өюдә ярышкан. Инвалидлар арасында узган һөнәри осталык буенча «Абилимпикс» илкүләм чемпионатында җиңүчеләрне һәм призерларны бүләкләделәр. Бүләккә – сертификат! Беренче урынга – 100, икенче урынга – 75, өченче урынга – 50 мең сум. Бу акчаны алар нәрсәгә тотарга җыена?

Финал ярышы 28–31 октябрьдә Мәскәүдә узган бәйгедә Татарстан җыелма командасы икенче урынны яулады.

– Бу – гадәти булмаган чемпионат. Пандемия сәбәпле, 2021 елда ярышның финалы булмады, шуңа күрә бәйге ике ел нәтиҗәләре буенча үтте. Быел безнең җыелма команда зур иде, анда 290лап кеше чыгыш ясады. Барлыгы 79 юнәлештә көч сынаштылар. Нәтиҗәдә 225е төрле дәрәҗәдә медальләр яулады. Сез – нык рухлы, көчле кешеләр. Өйрәнгән һөнәрегез гомер буена җитәр, – диде Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Андрей Поминов тәбрикләү тантанасында.

Илгизәр Хәмидуллин чүлмәк ясау эше буенча беренче урын алган. Аның күзләре күрмәү бу эшкә комачаулык итми.

– Татарстанны ил күләмендә танытасы килгән иде, теләгем кабул булды. Хәзер Россияне дөньяга күрсәтәсе килә, – диде, үзен чүлмәкче малай дип таныштырган җиңүче. – Грантлар заманы бит. Мәгариф үзәге грант отып, чүлмәк ясарга өйрәтү буенча курс ачкан иде. Без 20ләп кеше шунда шөгыльләндек. Ерак булгач, таксида йөрдем. Грант бетте: шөгыль һәм теләк калды. Аннан башка остаханәгә язылдым. Зөягә барып, бер атна укып кайттым. Ике елдан бирле мин шушы эштә.

Беренче чүлмәге 3 кило авырлыкта булган. Аны Рамил хәзрәт Юныс яхшы гына бәядән сатып алган. «Югыйсә аңа кирәкмәгәндер дә инде ул, күңелемне күтәрергә теләгәндер. Шундый олы җанлы кешеләр булганда, эшлисе генә килеп тора. Ясаган чүлмәкләрнең санын оныттым, йөзләп бардыр», – ди Илгизәр Хәмидуллин.

Мамадыш көллиятендә белем бирүче Мансур Һадиев үзе дә, шәкертләре дә ярышта бик теләп катнаша. Аларны ул акшарлау, кирпеч өю серләренә өйрәтә. Моңа кадәр республика этабында җиңсә, быел ил күләмендә беренче урын алган. Биремнәр җиңел булмаган: койма өйгәннәр, кирмәннәр ясаганнар.

– Без, инвалидлар, бирешмибез. Өйдә ятып нишләр идең? Ә мондый чемпионат булганда, төшенкелеккә бирелмисең. Үзе бер көч бирә, – ди Мансур Һадиев. – Бу – минем әти өйрәткән һөнәр. Кечкенәдән үзе белән төзелешкә йөртте. «Өйрән, улым, кирәге чыгар», – дип кабатлый иде. Менә бит кирәге чыкты!

Фәридә Гайнетдинова – Арча педагогика көллияте мөгаллиме, әлеге ярышларны бәяләүче белгеч. Технология укытучысы студентларны ыргак һәм энә белән бәйләргә өйрәтә. Аның студенты Ләйлә Гайнетдинова быел беренче урынны алган.

– Хәзер бит авыру һәм сәламәт балалар бергә укый. Көллият базасында гимназия сыйныфлары бар. Булачак башлангыч сыйныф укытучыларын да бәйләргә, тегәргә, чигәргә өйрәтәбез. Теләгәннәр төбәк чемпионатында катнаша. Төннәрен йокламыйча эшләгәннәре дә бар, – ди остаз.

Ләйлә Гайнетдинова әлеге бәйгедә башта көмеш медаль яуласа, быел «алтын»лы булган. Ул Урта Курса мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты дәресләрен укыта.

– Кечкенәдән күзләрем авырта. Танышлар, көллияттә гимназия сыйныфлары ачылган, дигәч, шунда укыдым. Ыргак белән бәйләргә өйрәндем. Ошап китте, кул үзеннән-үзе шуңа ята башлады. Муенса, урындык япмасы, итәк, сумка бәйләдем. Әле сатарлык түгел, осталыкны арттырам, – диде 20 яшьлек Ләйлә.

Аннан: «Сертификатны нәрсәгә сарыф итәргә җыенасың?» – дип тә сорадык. Ул икеләнеп калды...

– Аптыраган, төгәл генә әйтә дә алмыйм. Бәйге шарты буенча аны белем алуга йә тернәкләндерү өчен техникага тотып була. Миңа боларның берсе дә кирәк түгел. Хәзерге вакытта читтән торып Мәскәү финанс-сәнәгать институтында укыйм. Елына 37 мең сум акча түлим. Тәкъдим ителгән уку йортлары арасында минеке юк. Шулай ук үзем өчен курслар үтәм. Акчага әйләндереп булса, ичмаса, җеп яки техникага тотар идем, – ди Ләйлә Гайнетдинова.

Сәрия МИФТАХОВА

Тарих битләреннән

КАЗАНДА СУВОРОВ ЭЗЛӘРЕ

Ноябрь ахырында сугыш хәрәкәтләрен сәнгать дәрәҗәсенә күтәргән Россия генералиссимусы Александр Суворов дөньяга килгән. Тарихка ул – бернинди сугышта да җиңелүне белмәгән бердәнбер хәрби җитәкче буларак кереп калган шәхес. Россия армиясе өчен бүген дә идеал булып кала бирә. Бөек полководец хакында меңнәрчә мәкалә, китаплар язылган. Аның батырлыгына ничәмә-ничә буын мөкиббән китеп, сокланып яши. Әмма, галимнәр әйтүенчә, аның тормышында ак таплар бихисап, без белмәгәннәре дә бик күп әле. Шуларның берсе, мөгаен, аның Казанда хезмәт иткән чорыдыр. Бигрәк тә безнең өчен. Александр Суворов Казан белән бәйле күренекле кешеләр арасында үзенең саллы урынын биләп тора.

Мәктәп яшендәге балалар өчен Суворов исемен йөртүче хәрби училищелар Бөек Ватан сугышы вакытында СССР Халык Комиссарлары советы карары нигезендә оештырыла. Бу эшнең инициаторы – генерал-лейтенант Игнатьев. Ул Сталинга хат яза һәм Мәскәүдә бер кадет корпусы оештырырга тәкъдим итә. Сталин исә бу тәкъдимгә ике төзәтмә кертә: училищеларга Суворов исемен бирергә һәм 9 шәһәрдә төзергә. 1943 елда – 11, 1944тә – 6, 1953тә – 1, 1955тә 1 училище ачыла. 1975 елда шуларның 8е гамәлдә була. 1991 елның 12 маенда Ульяновск һәм Бишкек шәһәрләрендә Суворов училищесын оештыру турында СССР Министрлар Кабинеты карары проекты әзерләнә. Моның нәтиҗәсе булып, Ульяновскидагы югары танк хәрби училищесы Суворов училищесы итеп үзгәртелә. СССР таркалу сәбәпле, Бишкек шәһәрендә оештырылмый кала.

Арча кырында өйрәнүләр

Ни кызганыч, Александр Суворовның Казандагы тормышын яктыртучы хатлар, документлар тулысынча табылмаган. Галимнәр моның төп сәбәбен 1815 елның 3 сентябрендә булган көчле янгын дип саный. Ул вакытта ут телләре торак йортлар урнашкан 70 кварталны ялмап ала. Нәтиҗәдә җирле губерна идарәсенең Казанны яулап алганнан бирле сакланып килгән архивы янып, көлгә әйләнә.

Генерал-поручик Суворов Казанга 1782 елның 20 гыйнварында Казан дивизиясе оештыру максаты белән җибәрелә һәм монда берничә ай була. Ул вакытта шәһәрнең таш биналардан торган үзәк өлеше әллә ни зур булмый. Дворяннар, түрәләр, сәүдәгәрләр Кремльдә һәм аның тирә-юнендә яши. Урамнарның озынлыгы бер чакрымнан артмый. Арча кыры дип аталган үзәк урам (хәзер Карл Маркс урамы) бүгенге Гоголь урамына кадәр генә була. Болак аръягындагы кварталлар 800 метрга гына сузыла. Мәгълүматлардан күренгәнчә, 1781–1782 елларда шәһәрдә 40000 чамасы кеше яшәгән.

Белгеч Евгений Панов тикшерүләреннән күренгәнчә, Суворов Казан губернаторы, генерал-майор, җиде елга сузылган беренче рус-төрек сугышында катнашкан Илья Бибиков белән рәсми төстә очраша. Бу яуда ул үзе дә булу сәбәпле, аларның сөйләшер сүзләре күп булган дип уйлыйк. Бибиков аны яңа герб белән таныштыра. Суворов һәр көнен догалар белән башлый һәм тәмамлый. Солдатларга да шундый таләп куя. Шуңадыр инде, аны Казан митрополиты Вениамин да кабул итә. Аңлашыла ки, шул ук вакытта ул подполковник, гарнизон артиллериясе командиры Семен Баратаев белән дә күрешми калмагандыр дигән фараз бар.

Казан дивизиясе командующие Суворов беренче көннән үк сугышчыларны өйрәтүгә көчен дә, вакытын да кызганмый. «Солдат тыныч вакытта да – сугышта» дигән гыйбарәне исеннән чыгармый, башкаларга да шуны тукып тора. Бигрәк тә төз ату һәм штык белән сугышу серләренә өйрәтә. Аның өчен солдатның, һөҗүмгә күтәрелеп, дошманына якын ук килеп, аны штык белән бәргәләп атуы кадерлерәк була. Өйрәнүләр, поход шартларына яраклаштырып, Арча кырында бара. Суворовның тырышлыгы бушка китми. Бу Казан дивизиясе катнашкан сугышларда бик ачык күренә. 1782 елның августында императрица Екатерина II Казан дивизиясен Днепр түбәнлекләрендәге Казыкирмән ныгытмаларына алып барырга һәм граф-де-Бальменнан Кырым гаскәрләрен кабул итәргә боера. Шулай итеп, Кырым һәм Ногай җирләренә һөҗүм башлана. 1782 елның 1 октябрендә составында Казан дивизиясе батальоннары да булган Суворов гаскәрләре ногайлыларны тулысынча җиңелүгә дучар итә. Морзаларның күбесе Суворовка баш ия һәм Кырымның Рус дәүләтенә кушылуын таный.

Хәрби эшчәнлеге

Александр Суворов 1742 елның 23 октябрендә гади солдат булып хезмәт итә башлый. Аннан сержант дәрәҗәсенә күтәрелә. 1754 елда беренче тапкыр офицер чинына лаек була. Бөек полководецның хәрби эшчәнлеге тарихка Җидееллык дип кереп калган яуда башлана. Россия бу чорда Австрия яклы булып, Пруссиягә каршы сугыша. Ул вакытта 27 яшьлек Суворов генерал-фельдмаршал Бутурлин командалыгындагы пехота полкларына җибәрелә һәм «Казан пехота полкы» комплектына кертелә. Казан пехота полкы исә 1700 елның 25 июнендә Петр I тарафыннан оештырылган була һәм ул барлык походларда да катнаша. Бу сугыш Суворов өчен зур тәҗрибә була. Хәрби коллегия вице-президентыннан яшерен ордер алгач, ул Әстерханга юл ала, Каспий диңгезе аша Һиндстанга юл яру өчен әзерләнә. Ике елга якын Каспий флотилиясен тәртипкә китерә. Әмма соңрак бу эшнең кирәге калмый. Менә шул вакытта ул Хәрби коллегиядән Казанга кайтырга дигән күрсәтмә ала да инде. Анда «Пугачев гаскәрләре эзе калган Казан җирлеген тәртипкә китерү өчен» дип языла. Югыйсә бу вакытта фетнә бастырылганга җиде ел чамасы вакыт үткән була инде. Тарихта язылганча, бу – зур походка чыгып китәр алдыннан бөек полководец өчен ял кебегрәк була.

Суворов җиңүләренең озын исемлеге 1799 елның сентябрендә Швейцариягә поход белән тәмамлана. «Рус штыгы Альп тауларын ертып керде ...» дип языла бу хакта соңрак әдәби әсәрләрдә. Суворов хәрби хезмәт иткән чорда алты тапкыр яралана, әмма бер тапкыр да сугыш кырын ташлап китми. Әле үзе исән чагында ук аның исеме легендага әверелә. Казаннан ерак булмаган Сокуры авылында (бүгенге Лаеш районы) дөньяга килгән Гавриил Державин аңа мәдхия җырлый.

Александр Суворовны Санкт-Петербургтагы Александр Невский лаврында җирлиләр. Кабер ташына бик кыска гына «Монда Суворов ята» дигән сүзләр уелган. Моны да Державин тәкъдим итә. Плитә өстендә Суворов полкларының байраклары җилферди.

Басурман

Суворов фамилиясенең килеп чыгышы турында версияләр күп төрле. Төрки телләргә кагылышлысы да бар. Кайбер интернет чыганаклары күрсәткәнчә, аның тамыры төрки телләрдәге «сувор» («җайдак») сүзеннән алынган дип санала. Суворовның хатларыннан күренгәнчә, ул татар телен дә, төрек телен дә яхшы белгән. Хәтта Евпаториядәге христианнар императрицага мондый хат җибәрәләр: «Суворов басурманга әйләнгән, кырым татарлары телен генә түгел, хәтта төрекләрнекен дә яхшы белә».

Башка версия буенча, Суворовлар 1622 елда Россиягә күченеп килгән шведлар нәселеннән дип санала. Әмма Евгений Панов бу версиягә каршы килә. «Чынлыкта Суворовлар Россиядә XV гасырдан бирле яшәгәннәр», – ди ул. Вячеслав Лопатин үзенең «Суворов» дип аталган китабында болай дип яза: «Суворов – ул исем түгел, ә киң таралган кушамат. «Сувор, суворый – ул шул ук «суровый» дигән сүз, ягъни ачулы, кырыс. Халык арасында бу сүз, мәсәлән, Тверь өлкәсендә кулланыла». Язучы фаразлавынча, 1323 елда Бөек Новгород Карелияне Швеция карамагына бирә, шведлар кулы астында яшисе килмәгән руслар аннан китә башлый. Бу гаиләләр арасында Суворовлар да була. Тарихи язмалардан күренгәнчә, аның әтисе Петр Iгә хезмәт иткән. Бик белемле булган, җиде телдә сөйләшә белгән яки аңлаган. Башта тәрҗемәче булган. Аннары, руслар басып алгач, аны Көнчыгыш Пруссиянең генерал-губернаторы итеп сайлыйлар.

Халык хәтере

Ничек кенә булмасын, берәүләр теленә күбрәк җәзалаучы булып кереп калганмы ул, икенчеләр өчен каһарманмы, генералиссимус Суворовның җиңүләре, исеме – ил тарихының аерылмас бер өлеше. Суворов традицияләренә тугрылык 1812 елгы Ватан сугышында Наполеонны җиңәргә ярдәм итә. 1941–1945 елгы Бөек Ватан сугышы вакытында өч дәрәҗәдәге Суворов ордены гамәлгә куела. Аның белән Совет Армиясенең катлаулы хәрби операцияләрне тормышка ашырган офицерлары һәм генераллары бүләкләнә. Сугыш чорында бу орденга 7111 кеше лаек була. Алар арасында Минзакир Әпсәләмов, Фатыйх Булатов, Василий Жданов, Алексей Панфилов, Гани Сафиуллин, Якуб Чанышев кебек якташларыбыз да бар.

Александр Суворов 50 елга якын кулыннан коралын төшермәгән. Инде менә өч гасыр буена аның батырлыгы, үрнәк булып, халык хәтерендә яши. Хәтердә генә түгел, исемнәрдә дә чагыла ул. Хәрби училищеның Суворов исемен йөртүе дә – шуның бер дәлиле. Башкалабызның Авиатөзелеш районында аның исемен йөртүче урам бар.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Сан

КАЗАН СУВОРОВ УЧИЛИЩЕСЫ

- Училище 1944 елның 30 сентябрендә 100әр кешедән торган дүрт рота һәм 50шәр кешедән торган ике әзерлек сыйныфы составында формалаша.
- 1944 елның 2 октябрендә дәресләр башлана.
- 1944 елның 8 ноябрендә Ирек мәйданында училищега Байрак һәм СССР Югары Советы грамотасы тапшырыла. Бу көн рәсми төстә Казан Суворов училищесының ачылган көне дип исәпләнә.
- 1949 елны беренче чыгарылышта училищены 65 суворовчы тәмамлый.
- Шушы чор эчендә училищеда 12 мең кеше белем ала. Бу уку йортын тәмамлаган 10 кеше Советлар Союзы Герое һәм Россия Герое исеменә лаек була. 60 кеше генерал званиесе ала. 11 кеше академик була, йөзләрчә кеше фәннәр докторы, фәннәр кандидаты исемен алуга ирешә. 1973 елда Казан Суворов училищесын Россия Федерациясе оборона министрының беренче урынбасары, Россия Герое, армия генералы Валерий Герасимов тәмамлый.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОННАРЫ

«Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешендәге 1 пунктында «якынча» сүзен «федераль» сүзенә алмаштырырга;

2) 10 статьяның 1 өлешендә «якынча уку-укыту программаларын» сүзләрен «федераль төп гомуми белем бирү программаларын һәм урта һөнәри белем бирүнең якынча уку-укыту программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

3) 11 статьяның 2 өлешендә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты» сүзләреннән соң «федераль башкарма хакимиятнең гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм аны гамәлгә ашыру, норматив-хокукый җайга салу функцияләрен башкаручы органы белән килештереп» сүзләрен өстәргә;

4) 15 статьяда:

а) 6 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда яшәүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучылар дәүләтнең тулы тәэминатында була һәм туклану, кием-салым, аяк киеме, йомшак һәм каты инвентарь белән тәэмин ителә. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларда яшәмәүче сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучылар мондый оешмаларны гамәлгә куючылар тарафыннан федераль бюджеттән бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка финанслау чыганаклары исәбеннән ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин ителә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 6[1] өлеш өстәргә:

«6[1]. Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары һәм муниципаль мәгариф оешмалары тарафыннан укыту өйдә оештырылган сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле белем алучыларны ике тапкыр түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибе, шул исәптән ике тапкыр түләүсез тукландыру акчалата компенсация белән алмаштыру мөмкинлеге, тиешенчә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 7[1] өлеш өстәргә:

«7[1]. I, II яки III төркем инвалидлар дип танылган затлар, урта һөнәри белем яисә югары белем алганнан соң, федераль бюджеттән бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы бюджетыннан, җирле бюджетларның бюджет ассигнованиеләре исәбеннән башка һөнәр, белгечлек яисә әзерлек юнәлеше буенча Федераль законда тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белемне беренче тапкыр алучы затлар өчен билгеләнгән тәртиптә тиешле дәрәҗәдәге һөнәри белем алырга хокуклы.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 01 декабрь, № 84-ТРЗ

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» 2014 елның 7 мартындагы 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 3; 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 60 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның беренче абзацында «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26^{3-3} статьясы» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) салымнарны (җыемнарны) билгеләү, гамәлгә кертү яисә аларның гамәлдә булуын туктату, салым ставкаларын (җыемнар ставкаларын), салымнар (җыемнар) түләү тәртибен һәм вакытын үзгәртү, салым ташламаларын (җыемнар буенча ташламаларны) һәм (яисә) аларны куллану нигезләрен һәм тәртибен билгеләү (юкка чыгару) турында Татарстан Республикасы законнары проектлары;»;

б) 2 пунктта «хокук мөнәсәбәтләрен» сүзләрен «мөнәсәбәтләрне» сүзенә алмаштырырга;

3) 3[1] статьяның 1 өлешендә «Россия Федерациясендә мәҗбүри таләпләр турында» 2020 елның 31 июлендәге 247-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләрен «федераль законда» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 01 декабрь, № 85-ТРЗ

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш); 2014, № 10 (I өлеш); 2015, № 6 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 1 – 2, № 6 (III өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 50 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:

«20) сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зоналар территорияләрендә төзелгән индустриаль (сәнәгать) паркларның Татарстан Республикасында Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән идарәче компанияләре – индустриаль (сәнәгать) парк эшчәнлеге максатларында булдырылган һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан файдалануга тапшырылган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 3[1] өлеш өстәргә:

«3[1]. Салым исәпләнгән салым суммасының 50 проценты күләмендә түбәндәгеләр тарафыннан түләнә:

1) сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зоналарның идарәче компанияләре – махсус икътисадый зонаның төзү турындагы килешүләре гамәлгә ашыру максатларында булдырылган һәм идарәче компания балансында төп чаралар объекты буларак салына торган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтнең исәпкә куйган айдан соң килә торган айдан башлап ун ел узгач, мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән;

2) сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зоналар территорияләрендә төзелгән индустриаль (сәнәгать) паркларның Татарстан Республикасында Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән идарәче компанияләре – индустриаль (сәнәгать) парк эшчәнлеге максатларында булдырылган һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан файдалануга тапшырылган мөлкәткә карата, күрсәтелгән мөлкәтнең исәбен аерым алып бару шарты белән.»;

2) 5 статьяда:

а) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2026 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 20 пунктын, 3[1] өлешен, 3[1] өлешенең 1 пунктын;»;

б) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) 2029 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 3[1] өлешенең 2 пунктын.».

2 статья

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасындагы дүртенче абзацыннан тыш, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктының «б» пунктчасындагы дүртенче абзацы 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 01 декабрь, № 86-ТРЗ

«Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнүе өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 21 июнендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2022, № 49 (I өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4[1] пункт өстәргә:

«4[1]) туплау бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре торак пункт чикләренә кертү мөмкинлеге йә бакчачылык территорияләре чикләрендә яңа торак пункт барлыкка килү мөмкинлеге бирә торган таләпләрне раслау;»;

2) 5 статьяның 1 пунктына «, шулай ук ведомство максатчан программалары эшләү һәм раслау» сүзләрен өстәргә;

3) 6 статьяның 1 өлешендә:

а) 2 пунктта «, шул исәптән инвестиция программаларын» сүзләрен «(шул исәптән инвестиция программаларын), шулай ук ведомство максатчан программаларын» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 6[1] пункт өстәргә:

«6[1]) ширкәт әгъзаларының гомуми җыелышында тавыш бирүне үткәрү өчен мәгълүмат системаларыннан файдалану максатларында аларны булдыру йә гамәлдәгеләрне үстерүне тәэмин итү;».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 01 декабрь, № 87-ТРЗ

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә
органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә
алу вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

Җирле үзидарә органнары тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы

1. Әлеге Методика җирле үзидарә органнары тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары (алга таба шулай ук – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен каралган.

2. Муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары, шул исәптән алар составына керә торган әлеге Законга 1 нче кушымтада күрсәтелгән шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары, тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә бирелә.

3. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме (Vсуб) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{суб} = \sum V_{субi},$$

монда:

$V_{субi}$ – i-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме.

4. I-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме ($V_{субi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{субi} = Z_{нi} + Z_{oi} + M_{зi},$$

монда:

$Z_{нi}$ – i-муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләренә (алга таба – хезмәткәрләр) хезмәт өчен түләү чыгымнары, хезмәт күрсәтү персоналыннан тыш;

Z_{oi} – i-муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген тәэмин итүче хезмәт күрсәтү персоналына (алга таба – хезмәт күрсәтү персоналы) хезмәт өчен түләү чыгымнары;

$M_{зi}$ – i-муниципаль берәмлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга башка чыгымнар.

5. I-муниципаль берәмлегендә хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнары ($Z_{нi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Z_{нi} = S_{н} \times Q_{нi},$$

монда:

$S_{н}$ – бер хезмәткәргә хезмәт өчен түләү чыгымнары, алар Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзәк аппаратларында әйдәп баручы консультант вазыйфасы өчен билгеләнгән вазыйфаи окладтан, дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда исәпкә алына торган түләүләрдән (тиешле финанс елына индексация ясауны исәпкә алып) һәм иминият кертемнәреннән чыгып санала;

$Q_{нi}$ – i-муниципаль берәмлегендә хезмәткәрләрнең норматив саны.

6. I-муниципаль берәмлегендә хезмәткәрләрнең норматив саны ($Q_{нi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Q_{нi} = \frac{T_{oi}}{T_{норм}} \times K_{расi},$$

монда:

T_{oi} – i-муниципаль берәмлегендә граждан хәле актларының һәм юридик әһәмияткә ия башка гамәлләрнең барлык күләмен башкару өчен кирәкле гомуми вакыт, ул Россия Федерациясе территориясендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты нигезендә гамәлләрнең һәр төре буенча санала;

$T_{норм}$ – елда эш вакыты нормативы, ул 1980 сәгать (елда 247,5 эш көне х көненә 8 эш сәгате) тәшкил итә;

$K_{расi}$ – i-муниципаль берәмлегендә халыкны урнаштыру коэффициенты.

7. I-муниципаль берәмлегендә халыкны урнаштыру коэффициенты ($K_{расi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_{расi} = \frac{И_i + 1}{И + 1},$$

монда:

$И_i$ – халык саны 500 кешегә кадәр булган i-муниципаль берәмлеге торак пунктларында яшәүче халыкның i-муниципаль берәмлегендә территориаль статистика органы мәгълүматлары буенча соңгы хисап елы ахырына даими яшәүче халыкның гомуми санында чагыштырма күләме;

И – халык саны 500 кешегә кадәр булган торак пунктларда яшәүче халыкның Татарстан Республикасы барлык муниципаль берәмлекләрендә территориаль статистика органы мәгълүматлары буенча соңгы хисап елы ахырына даими яшәүче халыкның уртача гомуми санында чагыштырма күләме.

8. I-муниципаль берәмлегендә хезмәт күрсәтү персоналына хезмәт өчен түләү чыгымнары (Z_{oi}) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Z_{oi} = S_{oi} \times Q_{oi},$$

монда:

S_{oi} – i-муниципаль берәмлегендә хезмәт күрсәтү персоналы булган бер затка хезмәт өчен түләү чыгымнары, алар минималь хезмәт хакы күләменнән һәм иминият кертемнәреннән чыгып санала;

Q_{oi} – i-муниципаль берәмлегендә хезмәт күрсәтү персоналының саны, ул соңгы өч елда i-муниципаль берәмлегендә хезмәткәрләрнең норматив санында хезмәт күрсәтү персоналының факттагы уртача санынннан чыгып санала (биш елга бер тапкыр яңадан карала).

9. I-муниципаль берәмлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бүтән чыгымнар ($M_{зi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$M_{зi} = M_{зкi} \times T,$$

монда:

$M_{зкi}$ – i-муниципаль берәмлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга, төзәтмәләр коэффициентыннан тыш, башка чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$M_{зкi} = (Z_{нi} + Z_{oi}) \times 0{,}2;$$

T – төзәтмәләр коэффициенты, ул, Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттән бирелә торган субвенциянең гомуми күләменнән тайпылган очракта, граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга башка чыгымнарны исәпләү өчен кулланыла һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$T = \frac{[V_{субФБ} - \sum_{i=1}^{45}(Z_{нi} + Z_{oi})]}{\sum_{i=1}^{45} M_{зкi}},$$

монда:

$V_{субФБ}$ – Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттән бирелә торган субвенция күләме.»;

2) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә
органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә
алу вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү методикасы

1. Әлеге Методика Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән, әлеге Законга 1 нче кушымтада күрсәтелгән шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү өчен кулланыла.

2. Шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә шәһәр яисә авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган субвенция ($V_{пос}$) күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{пос} = \sum_{j=1}^{n} V_{посj},$$

монда:

$V_{посj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлеге бюджетына Татарстан Республикасы i-муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган субвенция күләме.

3. J-шәһәр яисә авыл җирлеге бюджетына Татарстан Республикасы i-муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган субвенция күләме ($V_{посj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{посj} = Z_{нj} + Z_{oj} + M_{зj},$$

монда:

$Z_{нj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләренә (алга таба – хезмәткәрләр) хезмәт өчен түләү чыгымнары, хезмәт күрсәтү персоналыннан тыш;

Z_{oj} – j-шәһәр яисә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген тәэмин итүче хезмәт күрсәтү персоналына (алга таба – хезмәт күрсәтү персоналы) хезмәт өчен түләү чыгымнары;

$M_{зj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга башка чыгымнар.

4. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнары ($Z_{нj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Z_{нj} = S_{нj} \times Q_{нj},$$

монда:

$S_{нj}$ – бер хезмәткәргә хезмәт өчен түләү чыгымнары, алар Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзәк аппаратларында әйдәп баручы белгеч-эксперт вазыйфасы өчен билгеләнгән вазыйфаи окладтан, дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда исәпкә алына торган түләүләрдән (тиешле финанс елына индексация ясауны исәпкә алып) һәм иминият кертемнәреннән чыгып санала;

$Q_{нj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәткәрләрнең норматив саны.

5. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәткәрләрнең норматив саны ($Q_{нj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Q_{нj} = \frac{T_{oj}}{T_{норм}} \times K_{расj},$$

монда:

T_{oj} – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә граждан хәле актларының һәм юридик әһәмияткә ия башка гамәлләрнең барлык күләмен башкару өчен кирәкле гомуми вакыт, ул Россия Федерациясе территориясендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты нигезендә гамәлләрнең һәр төре буенча санала;

$T_{норм}$ – елда эш вакыты нормативы, ул 1980 сәгать (елда 247,5 эш көне х көненә 8 эш сәгате) тәшкил итә;

$K_{расj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә халыкны урнаштыру коэффициенты.

6. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә халыкны урнаштыру коэффициенты ($K_{расj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_{расj} = \frac{И_j + 1}{И + 1},$$

монда:

$И_j$ – халык саны 500 кешегә кадәр булган j-шәһәр яисә авыл җирлеге торак пунктларында яшәүче халыкның муниципаль берәмлектә территориаль статистика органы мәгълүматлары буенча соңгы хисап елы ахырына даими яшәүче халыкның гомуми санында чагыштырма күләме;

И – халык саны 500 кешегә кадәр булган торак пунктларда яшәүче халыкның муниципаль берәмлекнең барлык җирлекләрендә территориаль статистика органы мәгълүматлары буенча соңгы хисап елы ахырына даими яшәүче халыкның уртача гомуми санында чагыштырма күләме.

7. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү персоналына хезмәт өчен түләү чыгымнары (Z_{oj}) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Z_{oj} = S_{oj} \times Q_{oj},$$

монда:

S_{oj} – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү персоналы булган бер затка хезмәт өчен түләү чыгымнары, алар минималь хезмәт хакы күләменнән һәм иминият кертемнәреннән чыгып исәпләнә;

Q_{oj} – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү персоналы саны, ул соңгы өч елда j-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәткәрләрнең норматив санында хезмәт күрсәтү персоналының факттагы уртача санынннан чыгып санала (биш елга бер тапкыр яңадан карала).

8. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бүтән чыгымнар ($M_{зj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$M_{зj} = (Z_{нj} + Z_{oj}) \times 0{,}2.».$$

2 статья

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) гамәли көче Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын формалаштырганда барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләренә 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджетлардан башлап кагыла.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 01 декабрь, № 88-ТРЗ

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә кабул ителде

1 статья

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 4[1] пункт өстәп, үзгәреш кертергә:

«4[1]. Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән төп гомуми, урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, уку чорында ата-анасын яисә берләнбер атасын йә анасын югалткан затларга тулы дәүләт тәэминаты («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган тәртиптә торак урыны бирүдән тыш) белән бердәттән, аларның әлеге уку-укыту программалары буенча укулары тәмамланганчы, уку әдәбияты һәм язма әсбаплар сатып алуга өч айлык дәүләт социаль стипендиясе күләмендә еллык пособие түләнә.».

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 01 декабрь, № 89-ТРЗ

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең
30 ноябрь, 2022 ел, № 6/34 карарына кушымта

Татарстан Республикасы Азнакай районы территориясендә оештырылган № 553 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы Теләче районы территориясендә оештырылган № 2693 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составы резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, 2022 елның 5 декабреннән 16 декабрьгә кадәрге чорда эш көннәрендә 08.00–17.00 сәгатькәчә (төшке аш вакыты: 12.00–13.00), Татарстан Республикасы Азнакай районы территориясендә оештырылган № 553 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе, Татарстан Республикасы Теләче районы территориясендә оештырылган № 2693 сайлау участогының участок сайлау комиссиясе составы резервына өстәмә рәвештә кертү өчен кандидатуралар буенча тәкъдимнәр җыю турында хәбәр итә.

Территориаль сайлау комиссиясе (ТИК) атамасы	Территориаль сайлау комиссиясе адресы
Татарстан Республикасы Азнакай районы ТИК	423330, Азнакай ш., Ленин ур., 22 й., тел.: (85592) 7-19-63, 7-24-12
Татарстан Республикасы Теләче районы ТИК	420080, Теләче ав., Ленин ур., 46 й., тел.: (84360) 2-14-34

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларына һәм референдумда катнашу хокукына төп гарантияләр турында» Федераль законның 29 статьясындагы 1 пунктындагы таләпләргә туры килмәүче затлар кертелми. Тәгаенләп әйткәндә:

– Россия Федерациясе гражданлыгына ия булмаучы затлар, шулай ук чит ил гражданлыгына яки анда яшәү өчен рөхсәткә ия булучы яисә Россия Федерациясе гражданинының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документка ия булучы Россия Федерациясе гражданнары;

– законлы көченә кергән суд карары нигезендә эшкә сәләтсез, эшкә сәләте чикләнгән дип танылган Россия Федерациясе гражданнары;

– 18 яшькә җитмәгән Россия Федерациясе гражданнары;

– дәүләт хакимияте законнар чыгару (вәкиллекле) органнары, җирле үзидарә органнары депутатлары;

– сайланылулы вазыйфаи затлар, шулай ук җирле хакимиятләр башлыклары;

– судьялар (отставкадагы судьялардан тыш), прокурорлар;

– суд карары нигезендә комиссияләр составыннан чыгарылган затлар, шулай ук комиссияне тарату нәтиҗәсендә хәлиткеч тавыш хокукы белән комиссияләр әгъзалары вәкаләтләрен җуйган затлар (комиссия тарафыннан закон бозулар өчен суд тарафыннан үзләренә карата гаепләрнең юклыгы билгеләнгән затлардан тыш) – тиешле суд карары законлы көченә кергәннән соң биш ел эчендә;

– үзләреннән хөкем җәзасы алынмаган затлар, шулай ук сайлаулар һәм референдумнар турында законны бозган өчен суд тәртибендә административ җәзага тартылган затлар – административ җәза билгеләү турында суд карары законлы көченә кергәннән соң бер ел эчендә, кандидатуралары кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертү өчен кирәкле документлары булмаган кандидатуралар участок сайлау комиссияләре составлары резервына кертелми.

Участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар буенча тәкъдимнәр кертү өчен кирәкле документлар исемлеге

Сәяси партияләр, аларның төбәк бүлекләре, башка структур подразделениеләре өчен:

1. Сәяси партиянең яки төбәк бүлегенең, сәяси партиянең башка структур подразделениесенең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында сәяси партия уставы таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

2. Кандидатуралар турында тәкъдим сәяси партиянең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе тарафыннан кертелеп, сәяси партия уставында мондый тәкъдим кертү мөмкинлеге күздә тотылмаганда – сәяси партиянең төбәк бүлегенә, башка структур подразделениесенә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертүгә вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле сәяси партия органының әлеге вәкаләтләрне бирү турында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары.

Башка иҗтимагый берләшмәләр өчен:

1. Иҗтимагый берләшмәнең гамәлдәге уставының нотариуста расланган яки иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле органы раслаган күчермәсе.

2. Иҗтимагый берләшмәнең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү хакында устав таләпләре нигезендә рәсмиләштерелгән карары яисә төбәк бүлегенең вәкаләтле (җитәкче яки башка) органының яисә иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә иҗтимагый берләшмә исеменнән мондый карар кабул итүгә хокук бирелгән иҗтимагый берләшмәнең башка структур подразделениесе карары.

3. Кандидатуралар турында тәкъдимне иҗтимагый берләшмәнең төбәк бүлеге, башка структур подразделениесе кертеп, иҗтимагый берләшмә уставында 2 пунктта күрсәтелгән мәсьәлә җайга салынмаганда – иҗтимагый берләшмә уставы нигезендә участок сайлау комиссияләре составлары резервына кандидатуралар турында тәкъдимнәр кертү буенча вәкаләтләр бирүгә вәкаләтле иҗтимагый берләшмә органының мондый вәкаләтләрне бирү турында карары һәм әлеге вәкаләтләр бирелгән органның участок сайлау комиссияләре составлары резервына тәкъдимнәр кертү турында карары.

Участок комиссияләре составлары резервына кандидатуралар кертү хокукының башка субъектлары өчен

Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары, яшәү, эшләү, хезмәт итү, уку урыны буенча сайлаучылар җыелышының беркетмәсе. Сайлаучылар җыелышы беркетмәсенең формасы Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, № 108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә № 3 кушымтада китерелгән.

Моннан тыш кандидатуралар кертү хокукының барлык субъектлары тарафыннан түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:

1. Россия Федерациясе гражданинының хәлиткеч тавыш хокукы белән участок сайлау комиссиясе әгъзасы итеп билгеләнүенә, участок комиссияләре составлары резервына кертүгә язмача ризалыгы (Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясенең 5 декабрь, 2012 ел, № 152/1137-6 карары (Россия Үзәк сайлау комиссиясенең 1 ноябрь, 2017 ел, № 108/903-7 карары редакциясендә) белән расланган Участок комиссияләре составлары резервын формалаштыру һәм участок комиссияләре составлары резервыннан участок комиссиясенең яңа әгъзасын билгеләү тәртибенә № 1 кушымта).

2. Россия Федерациясе гражданины паспорты яки кандидатурасы участок комиссияләре составлары резервына кертү өчен тәкъдим ителгән затның гражданлыгы һәм яшәү урыны турында мәгълүматлардан торган Россия Федерациясе гражданины паспортын алыштыручы документы күчермәсе.

Искәрмә. Документлар үрнәкләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына «Сайлау комиссияләре» бүлегендәге «Участок комиссияләре составлары резервы» «2022 елда участок сайлау комиссияләре составлары резервына өстәмә кертү» бүлекчәсенә урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе

РОЗА ҺӘМ АНЫҢ БАБАСЫ

Буыннар чылбыры

Дәүсоветның матбугат үзәге икенче эш урыным кебек. Көн саен шунда сугылмыйча калмыйм. Фикердәшләрем белән чәй өстәле янында соңгы яңалыклар турында сөйләшеп, аларга үз бәябезне биреп, киңәшләшеп утырабыз.

Беркөнне матбугат үзәгенә яңа кыз килде. Күл буенда үскән зифа камышка охшатып, җырлап кына торырлык кыз иде ул. Исеме – Роза. Сарман районының Җәлил бистәсеннән икән. «Кыз» дип яздым язуын да, аның инде ике баласы бар икән.

Менә шул сылу кыз, дөресрәге, ханым беркөнне, Сарманга кайтасы бар дип, бәргәләнеп йөрде. Яңа кеше булгач, хуҗадан, ягъни матбугат үзәге җитәкчесеннән сорап китәргә дә кыенсына иде ул. Чөнки парламент эшчәнлегенә бәйле вакыйгалар бер-бер артлы була тора һәм алар турында вакытында язып барырга кирәк.

Мин Розадан: «Берәр нәрсә булмагандыр бит?» – дип сорадым. «Булмады, әмма булырга тора», – дигән иде ул. Баксаң, бабасы Габделәхәт Исмәгыйлевнең туган көненә ашкына икән Роза. Ире дә, ике баласы да кайтмакчы икән.

Бабасының 95 яшьлек юбилеен бик зур вакыйга итеп санавы сокландырды да, уйландырды да. Бер уйлаганда, бала-оныкларның юбилейларга кайтуы табигый инде ул. Әмма, икенче яктан, бабасына булган олы хөрмәт өстенә, Роза аның тормыш юлын, биш бармагы кебек дигәндәй, белә булып чыкты. Алай гына да түгел, бабасы турында берсеннән-берсе кечкенә ике баласына да сөйли икән.

Сугыш ветераны Габделәхәт абзый хакында биш һәм сигез яшьтәге кызларына ниләр хакында, ничек итеп сөйләгәннәре турында төпченмәдем, әмма сабыйлар күңеленә өлкән буын вәкиленә мәхәббәт хисе сеңдерү юлын тапкандыр Роза. Юкса ике сабые да «безнең бабай, безнең бабай» дип яратып сөйләмәсләр иде.

Ә «безнең бабай», ягъни Габделәхәт Гыйльфанетдин улы Исмәгыйлев тугыз яшеннән колхоз атларын көтә башлый. Дәрестән соң да әтисенә атлар карарга булыша. Үз авылларында башлангыч белем ала, ә 15 яше тулгач, 1942 елда аны ФЗӨгә укырга җибәрәләр. Ул чор балалары кебек Габделәхәт тә, корал тотып, илен саклау турында хыялланган. Аңа, әлбәттә инде, башың яшь дип әйтми калмаганнар. Аның каравы ФЗӨдә укыганда Габделәхәт, станок янына басып, сугыш кораллары өчен детальләр ясый башлый. Һәм, җиңүгә мин дә үз өлешемне кертәм, дип, күңелен бераз тынычландырмый калмагандыр.

Ә Казаннан авылына кайтып бер атна узуга, аңа күптән көтелгән хәбәр – сугышка повестка килә. 17 яшь тулып, нибары ике көн узган була Габделәхәткә. Егетебез, үзе әйтмешли, «биштәренә бар булган ризыкны салып», сугышка китә. Әмма сугыш кырына әләкми әле, яңа алынганнарны төрле частьларга тарата башлыйлар, ә аны Таҗикстанга, чик буе гаскәрләренә җибәрәләр. Бу – 1944 елның декабре. Яшь солдат ни

өчен сугыштан бик еракка җибәрелгән? Тарихны искә төшерсәк, Бөек Ватан сугышы елларында Таҗикстан белән чиктәш Әфганстан үзара сугышучы яклар разведкасы өчен «стратегик буфер» хезмәтен үти. Әле Беренче Бөтендөнья сугышы елларында ук немец генштабы бирегә үз разведчиклары һәм белгечләренең махсус отрядын җибәрә. Өченче Рейхның Әфганстанга мөнәсәбәтле рәвештә үз максаты була. Монда Абвер һәм Япония шпионнары мыжлап тора һәм, СССРны тар-мар иткәч, Гитлер Урта Азия совет республикаларына тотынырга тели. Ә шпионнар, мораль җирлек әзерләү өчен дигәндәй, әлеге республикаларга каршы корткычлык алып баралар. Германия, Япония, Бөекбритания хакимлеккә совет властеның дошманы булган басмачыларны китерергә телиләр. Кыскача тарих менә шундый. Ә «көтелмәгән кунаклар»ны совет чик сакчылары каршы алырга тиеш була.

Габделәхәт солдат ул чордагы вазгыятьне тирәнтен белмәгәндер дә. Истәлекләр уртаклашканда: «Безнең застава «Айкуль» дип атала иде, передовойга керергә резерв идек», – дип кенә әйтә. Әмма чик буе гаскәрләрен гел алгы сызыкта дип санарга мөмкин. Сугыш вакытында чик сакчылары иң авыр шартларда шпионнарны, диверсантларны, бандит шайкаларын аулыйлар. Рәсми мәгълүматларга караганда, Таҗикстан чигендәге бер отрядка гына да аена 400 чик бозучы туры килә.

Габделәхәт аганың кызы Рәисә әйтүенчә, ветеран сугыш турында сөйләргә бик яратмаган. «Сугыш» дигән сүзне үк җене сөймәгән аның. Күкрәге тулы дәүләт бүләкләре булса да, батырлыклары турында да мактанырга яратмый икән ул. Бөтен сүзе: «Үз бурычыбызны үтәдек». Солдатның «үз бурычын үтәве» 8 елга сузыла. 1948 елда Ашхабадта җир тетрәгәч, аларны шунда шәһәрне җимерекләрдән чистартырга җибәрәләр.

Солдат бары тик 1951 елның язында гына туган якларына әйләнеп кайта. Бу вакытта сугыш ветеранына нибары 24 яшь була. Яшьлекләрен сугыш уты көйдергән буын – Габделәхәтләр буыны инде ул. Баштарак Азнакайда, туган авылы Буралыда колхозда эшли солдат. Аннан соң Сарман районында Җәлил бистәсе төзелгәч, шунда күчә һәм гомерен нефть чыгаруга багышлый.

Үзе аз сүзле булгач, мин кайбер мәгълүматларны аның кызы, 30 ел балалар укыткан Рәисәдән алдым. Әтисенең артык тыйнаклыгына ул да шакката. Нишлисең, ил чакырса, утка-суга керү әлеге буын өчен бары тик Ватан алдында үз бурычын үтәү генә саналган, күрәсең. Сугыштан соң җимерекләрне торгызу, икмәк үстерү, «кара алтын» чыгару да бары тик изге бурыч кына исәпләнгән андый егетләр өчен. Кызы Рәисә, оныгы Роза әйтүенчә, бүген Украинада барган махсус хәрби операция турында сүз чыккач та: «Их, яшьрәк булсам, мондый чакта өйдә утырыр идеммени…» – дип куйгалый икән карт солдат. Алар шулай тәрбияләнгән инде, дөресрәге, аларга тормыш үз сабагын биргән.

Без еш кына әти-бабалар рухын саклау турында сөйләшәбез. Роза Зарипова да, аның әнисе Рәисә дә – буыннар чылбырын саклаучылар. Ата-бабалар рухына тугрылыклы булып калуны алар да изге бурыч дип кабул итә кебек. Юкса Габделәхәт солдат турында рухланып, яратып сөйләмәсләр, балаларын да шулай тәрбияләмәсләр иде.

Минем Габделәхәт абыйга, гомумән, Ватан солдатларына озын гомер телисем килә. Әмма, ни кызганыч, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның саны еллап түгел, айлап кими бара. Интернетта хәзерге көндә исән ветераннарның саны турында мәгълүмат таба алмадым. Быелның май аенда алар 223 кеше булган. Ә хәзер… Ватан солдатлары белән бергә тарихи хәтер, тарихи гыйбрәт китеп бара. Алар – булып узган вакыйгаларның тере шаһитлары.

Бу язмамны тәмамлар алдыннан күптәнге дустым, «кайнар нокта»ларда булган офицер, запастагы полковник Рөстәм Гомәровка шалтыраткан идем. Габделәхәт абый, аның кызы Рәисә, оныгы Роза турында сөйләдем. Сокланды ул бу нәселгә. Рөстәм Казан техникумнарының берсендә укыта, үз ихтыяры белән патриотик тәрбия дәресләре дә алып бара. Мине тыңлап торды да: «Их, Риман абый, минем шәкертләрем арасында бабалары гына түгел, әтиләре турында берни белмәгәннәр дә бик күп», – диде. Буыннар чылбыры әнә шулай, тарихи хәтер бетеп өзелә инде ул.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Уртак казан

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Чыннан да, соңгы елларда кооперативларның яңа бер көч белән эшли башлауларын берничек тә инкарь итеп булмый. Чынлап торып эшләүчеләрнең саны елдан-ел арта. Үзебезгә дә гомер буе авылда эшләгән, колхозларның гөрләп торган һәм сүнгән вакытларын күргән җитәкчеләрдән дә, авылларның киләчәге – кооперативларда, дигән фикерне еш ишетергә туры килә. Чөнки кооперативның төп уңышы – җитештергән продукцияне берләшеп сатуда. Бердән, бәясе отышлы, икенчедән, чимал сату белән проблемалар юк. Авыл халкы терлеген, яшелчәсен үстерә дә алыпсатарларга түбән бәягә сатып җибәрә, аннан кергән акчасы чыгымнарны гына капларга җитә. Ә кооперативларга берләшкәндә, пайчы булып торган шәхси хуҗалык, фермер итен, сөтен үзе эшкәртә һәм сата ала. Моннан тыш, берләшү авылларда эш урыннары булдырырга, яшьләрне җәлеп итәргә, моңа кадәр буш, ташландык хәлдә булган җитештерү биналарын яңа тормышка кайтаруга да булыша.

Монда, билгеле, дәүләт ярдәменең өлеше дә зур. Әйтик, республикада ел саен кооперативларга 70 млн сумга кадәр грант бирелә. Конкурста керемнәренең 70 проценты кооператив эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган оешмалар катнаша ала. Әлеге акча гадәттә төзелеш, ремонт эшләре, җиһаз, контейнерлар, транспорт сатып алу өчен тотыла. Моннан тыш, тотылган чыгымнарга субсидияләр дә бирелә.

– Кооперативлар чыннан да үсә. Аларга кушылырга теләк белдерүчеләр дә арта. Итчелек, сөтчелек белән шөгыльләнүче фермерлар һәм шәхси хуҗалыклар аның отышлы булуына инанды инде, – ди Таһир Гомәров.

Без аннан кооперативлар оештыру белән актив шөгыльләнүче районнарны да белештек. Бу юнәлештә Кукмара, Саба, Арча районнары актив эшли булып чыкты. Ә менә Буа, Апас, Югары Ослан, Яшел Үзән, Алабуга районнарында алар аз яки гомумән юк диярлек.

– Кайда терлек күп, кооперативлар шунда оеша. Дәүләт ярдәмен алып, пайчылар эшләрен җиңеләйтер һәм уңышлырак эшләр өчен берләшә. Авыл хуҗалыгы көчле булган районнарда кооперативлар да гөрләп эшли, – ди ул.

БӘРӘКӘТЛЕ КАРТЛЫК

Бер-берләрен гомер буе кадерләп, саклап йөрткән матур парлар бар. Шундый күркәм парларның берсе – Чистай районының Дүртөйле авылында яшәүче Әминә һәм Ринат Сәлаховлар.

– Мин апагыз белән 1966 елда интернет аша таныштым бит, – дип шаккатырды башта безне Ринат абый. «Ул заманда нинди интернет булсын инде?» – диештек. Ә хикмәт менә нәрсәдә булган икән.

Ринат абыйның армиядән кайткан чаклары булган ул. Ә яшь кыз Әминәнең укуын тәмамлап, шушы авыл мәктәбенә балалар укытырга төшеп йөргән мәлләре.

– Иске өебезнең кечкенә генә тәрәзәләре бар иде. Бозга каткан шул тәрәзәне эретеп, кечкенә генә тишек ясап, ара-тирә урамны күзәтеп ала торган тәртибем бар. Бер көн шулай карап торганда, чаңгы шуып баручы бер кызга күзем төште. Янымдагы сеңлемнән аның кем булуын сорадым. Ул әлеге чибәр туташның яшь мөгаллимә булуын әйтте. Шул кечкенә генә тишектән бер күз төшереп алу җитте миңа апагызга гашыйк булыр өчен. Күңелдә ялкын кабынды бит. Шунда ук: «Бу кыз минеке булырга тиеш», – дигән уй керде. Ләкин тиз генә чыгып танышырга кыймадым. Безнең чорда гомумән ике яшь кешенең ялгызы гына калып сөйләшүе хупланылмый торган ят күренеш иде. Әминә укытырга күрше авылдан килеп йөрде. Ә мин колхозда шофер булып эшли идем. Ара-тирә машинага утыртып, алып кайтып куя башладым. Аралашуыбыз әнә шулай башланды безнең, – дип сөйләде Ринат абый.

Мәхәббәт тарихы башланырга сәбәп булган мәктәптә исә Әминә апа 41 ел эшләгән. Балаларга математика укыткан ул. Биш балаларының өчесе әниләре юлын сайлауда да аның өлеше булмый калмагандыр. Сәлаховлар династиясенең гомуми укытучылык стажы 106 елга тулган икән инде.

– Кызларыбызның өчесе дә үземнең юлдан китте. Олы кызыбыз Әнисә биология һәм химия укытты. Уртанчыбыз Рүзилә мәктәптә директор урынбасары булып эшли. Өченче кызыбыз Казанда белем бирде. Әлеге вакытта балалар бакчасында эшли. Үз юлымнан китүләренә сөендем генә. Эшем ияреп өйгә кайта иде, кызлар мөгаллим хезмәтен күреп үстеләр, – ди Әминә апа.

Авылларында мәктәп булмаса да, мәгариф өлкәсендәге яңалыклардан бүген дә хәбәрдар булып яши алар.

– Мәктәптә дә, гаиләдә дә, тормышта да берберәңә яхшылык эшләргә тырышырга, яхшы мөгамәләдә булырга кирәк. Үзебез эшләгәндә хезмәттәшләребез белән бик дус-тату яшәдек. Әле дә чордашларыбыз белән аралашып торабыз. Мәктәптә эшләгән елларны сагынып искә алабыз. Алар белән бергә эшләү рәхәт иде, бик актив булдык. Укучыларым да бик рәхмәтле булды. Килеп, хәлемне белешеп торалар, – ди Әминә апа.

Ринат абый да – гомерен авылга, авыл хуҗалыгына багышлаган кеше. Шофер да булган, бригадир булып та эшләгән, ә пенсиягә чыгар алдыннан 20 елын агрономлыкка багышлаган. Әлеге мөлаем, матур парның быел гаилә коруларына 55 ел булган. Кадерләп, саклап торырдай ныклы терәк булган биш балалары, җиде оныклары, дүрт оныкчыклары бар.

– Тормышыбыздан бик канәгать, пенсия килеп тора, балалар исән-сау, үзебез бәхетле, парлы гомер кичердек. Ураза тотабыз, намазлар укыйбыз, мәчеткә йөрибез. Болар үзе үк зур бәхет ләбаса, – дип шөкер итә Сәлаховлар бүгенге тормышларына.

Шулай булмыйни, ул әле дә машинасына утырып, кайчандыр тәрәзә ярыгыннан гына күзәткән Әминәсен дә янына алып, балаларының, оныкларының хәлен белешеп кайта. Өйләренә җиде-сигез газета яздырып, парлашып утырып укыйлар. Кадерле һәм бәрәкәтле тормыш шундый була торгандыр инде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

САГЫШ

Уйлы күңел

«…Кошларда да кеше язмышлары, Чит җирләргә китеп барышлары…» – дип җырлаганнарын ишетсәм, гел капка төбенә чыгып, хат ташучыны каршы алган авыл апалары күз алдыма килә минем.

Сәбәбе болайрак. Без бәләкәй чакларда әнием хат ташучы булып эшләгән иде. Күрше авылдан газета-журналларны алып кайту, кич белән аны таслап-таслап почта сумкаларына тутыру һәм иртүк атлый-йөгерә таратып кайту безгә – өй тулы бала-чагага йөкләнде. Һәрберебезнең үз урамнары, үз тыкрыклары бар. Юк, тиз-тиз генә үтеп булмый иде әле ул араны. Һәр гаиләдән балалар чит җирләргә киткәннәр, шунда гомер итеп яталар. Нинди генә шәһәрләр, республикалар юк инде анда: Магадан, Воркута, Свердловск, Чиләбе, Первоуральск, Донбасс, Хабаровск, Үзбәкстан, Таҗикстан… Кемнең кайсы баласы кайда яшәгәнне хәзер дә яттан беләм кебек. Хатлар да көн саен өем-өем килә. Ә апалар, әбиләр: «Укып бир инде, кызым», – дип көтеп торалар. Укый белмәгәннәрдер дисәм, бәлки, күзләре генә күреп бетермәгәндер. Кем белә инде? Кайберләре каршы хат язарга да чакыралар иде әле. Анысы инде җайлап, вакыт булганда. Менә шул вакытларда ук кереп калган күңелемә сагыш дигән хиснең ни-нәрсә икәнлеге. Балаларын, оныкларын бер күрергә тилмереп яшәгән аналар… Яшерен генә күз яшьләрен сөртеп, мышык-мышык елап алулар… Акча юклыктан туган авылга ике елга бер кайтып килергә генә мөмкинлек тапкан балалар…

Шул аналарны жәлләп, ул вакытта да ниндидер уйлар өермәсе кайный иде миндә: нишләп шундый еракка китеп барган алар? Шәһәргә китәм дисәң, Яшел Үзән, Казан тирәсендә калсалар да була бит инде. Башкалага ике сәгатьлек юл. Поезд йөреп тора. Анда киткәннәр дә фатир да юнәтәләр, атна саен кайтып та йөриләр бит. Әти-әниләренә дә рәхәт, үзләренә дә. Әмма тормышның үз законнары булгандыр, күрәсең. Нииндидер дулкын сыман иде ул. Ераграк киткән саен кәттәрәк тоела иде кебек. Күбесе туганнары, дуслары янына юл алдылар. Төпләнеп китәргә дә шулай җиңелрәк булгандыр, күрәсең. Уку йортларын тәмамлаганнарның күбесе юллама белән китеп барды. Югыйсә байлык көтеп тормаган аларны чит җирләрдә. «Тулай торакта яшибез, ел саен кайтырга акча җитеп бетми шул» дигән сүзләрне күп тапкыр ишеткәнем булды.

Соңгы елларда, заманалар да үзгәрде, мондый гадәт бетте дә диярлек. Күпләр туган җирдә яшәп калуны хуп күрделәр.

Авыл тарихы турында китап язгач, шул уйлар өермәсе янә калкып чыкты. Туган җиргә аяк баса алмыйча, сагышка күмелеп яткан авылдашлар шундый күп икән әле ул. Берәүләрнең балалары, оныклары шунда тормыш корган, аларны ташлап китеп булмый. Икенчеләрне сәламәтлек ташлаган… Кыскасы, мең төрле сәбәп.

…Күптән түгел Норлат авылында яшәүче дус кызым Гөлгенә шалтыратты. Аның әбисе Газзә апа безнең күршедә генә яшәде. Гөлгенә җәй саен әбисенә булышырга кайта иде. Кунаклар да күп кайта иде аларга. Әнисе Гөлшат апаның эне-сеңелләре – Зөмәрә апа, Гөлнур апа, Рәшит абый – барысы да бик еракта, чит җирләрдә. Бүген бары тик Зөмәрә апа гына исән-сау яшәп ята икән. Архангельскида япа-ялгыз калган икән ул. Ире үлеп киткән, кызлары ерак җирләргә кияүгә чыккан.

– Фәния, авыл тарихы турында берәр китабың калмадымы? Зөмәрә апага китап турында сөйләгән идем. Бик елады. Күрәсем килә, диде, – ди. Аннан янә сөйләштек. «Китапны алгач, төн буе йокламыйча елый-елый укыдым. Яшьлегемә кайтып килгән, урамнардан йөргән кебек булдым. Йөрәгем өзгәләнә. Күрмәгәнемә дә биш былтыр бит инде. Күрә дә алмам инде», – дигән Зөмәрә апа. Актанышта яшәүче күрше кызына да җибәргәннәр китапны. Операция ясатканнан соң күп еллар инде машинага утырып юлга чыга алмый. Ул да шундый хисләр кичергән. Инсульттан соң Яшел Үзәндәге фатирыннан чыгарга куркып яткан Рәйханә апа да: «Синең китапны укыгач, бернигә дә карамастан, авылга кайтасым килә башлады. Кайтам әле, кайтам, урамнарны булса да әйләнеп киләм», – дип хәбәр итте. Екатеринбург шәһәрендә яшәүче Фәнис абый да кайдандыр телефонымны табып шалтыратты. Әти-әнисе күптән бакыйлыкка күчтеләр инде. Шуннан бирле кайтканы юк икән. Аның да кайтасы, авылдашларын бик күрәсе килә булып чыкты.

Шулай шул. Алагаем зур Җир шарында синең туган-үскән җирең бер кечкенә генә нокта кебек. Беркем дә белми дә, беркемгә дә кирәкми дә кебек әле ул. Әмма шунда туып-үскән кеше өчен ул – барыбер газиз җир. Күптән түгел «Бесогон» тапшыруында Сергей Михалков, илен ташлап китүчеләр турында сөйләгәндә, бер акыл иясенең мондый сүзләрен китерде: «Аллаһы Тәгалә кодрәте белән синең кендек каның шушы җиргә тамган икән, бу юкка гына түгел, син ни өчендер бу җиргә кирәк». Хәер, кем икәнлегебезне аңлар өчен күп вакытта туган җиребез үзе кирәктер безгә. Күпме генә уйламаска, онытырга тырышсаң да, әллә кайсы күзәнәкләрдә «югалып торган» сагыну, сагыш дигән хисләр берзаман барыбер актарылып чыга… Туган җирен генә түгел, туган илен ташлап китүчеләр бу хакта ни уйлыйлар икән?

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА



Илдар Мөхәммәтҗанов

Бергә җыелганда

Балалар һәм әти-әниләр өчен махсус сәхифә

Тест

ЯРАТАМ МИН АП-АК ТӨСНЕ...

Иң матур ел фасылларының берсе – кышның беренче аена да аяк бастык. Җир өстендә, өй түбәләрендә, агачларда ап-ак кар ята. Елга-күлләр дә боз белән капланды инде. Ә сез бу ел фасылының үзенчәлекләрен беләсезме? Үзегезне сынап карагыз әле.

1. Кайсы кош кышын җылы якларга очып китми?
а) ләкләк;
б) карлыгач;
в) песнәк.

2. Кышкы спорт төренең кайсында тимераякта шумыйлар?
а) фигуралы шуу;
б) биатлон;
в) хоккей.

3. Яшел чыршы алып кайтып, аны бизәү гадәте кайда барлыкка килгән?
а) Германиядә;
б) Кытайда;
в) Америкада.

4. Кыш бабайның туган көне?
а) 25 гыйнвар;
б) 18 ноябрь;
в) 31 декабрь.

**5. Яратам мин ап-ак төсне,
Бөтен дөнья ап-ак төсле.
Куяннар да ак тун кигән,
Каеннар да ак туннан.**
Бу шигырь юлларының авторы кем?
а) Роберт Миңнуллин;
б) Ләбиб Лерон;
в) Әминә Бикчәнтәева.

6. «Беренче кар» картинасының авторы?
а) Иван Шишкин;
б) Бакый Урманче;
в) Александр Пластов.

Җаваплар: 1) в; 2) б; 3) а; 4) б; 5) а; 6) в.

ГАЗИНУР ГАЙНЕТДИНОВ:

«АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫН ҮСТЕРЕРГӘ ТЕЛИМ»

Бүгенге кунагыбыз – «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) илкүләм чемпионатында икенче урын яулап, Татарстан данын таныткан Сарман районының Әлмәт авылы егете Газинур ГАЙНЕТДИНОВ. Кечкенәдән техника җене кагылган егет киләчәген авыл хуҗалыгы белән бәйләргә тели.

:: Газинур, техника белән мавыгуың кайчан башланды?

– Мәктәптә укыган вакытта ук үзем двигательләрне сүтеп җыя идем инде. Әтием мине кечкенәдән һәрвакыт үзе белән ияртеп йөрде, техника серләренә төшендерде, бар эшкә ул өйрәтте. Моның өчен бик зур рәхмәт аңа.

:: WorldSkills чемпионатына ничек килеп эләктең?

– Чемпионат турында ишеткәнем бар иде. Мине, сәләтең бар, техниканы яхшы беләсең, дип катнашырга кыстадылар. Башта көллияттә узган ярышларда катнаштым. Аларда җиңгәннән соң, республика күләмендә беренчелекне яуладым. Аннан Мордовиянең Саранск шәһәрендә узган финал ярышларында Татарстан данын яклап чыгыш ясадым. «Авыл хуҗалыгы машиналарын эксплуатацияләү» компетенциясендә икенче урынга лаек булдым.

:: Ярышта ниндирәк биремнәр булды?

– Кыска вакыт эчендә техниканың төзексез җирләрен табып көйләү, аны эшләтеп җибәрү, техник хезмәт күрсәтү кебек биремнәр булды. Остазларыма, укытучыларыма бик зур рәхмәт. Минем җиңүемдә аларның өлеше зур.

:: Катнашучылар арасында иң яше дә бит әле син. Үзеңнән зурраклар белән көч сынашырга авыр булмадымы?

– Әйе, көндәшләрем миннән 2–3 яшькә олырак иде. Шуңа ярыш та җиңелләрдән булмады. Төрле шартларда эшләргә туры килде. Тик шулай да, мин үз эшемне төгәл һәм тиз итеп башкарып, республикада – беренчелекне, ил буенча икенче урынны яулый алдым. Әзерлек һәм тренировкаларга йөрү үз нәтиҗәсен күрсәтте.

КУНАГЫБЫЗ ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

- Газинурга – 18 яшь.
- Ул Сарман аграр көллиятенең 3 нче курсында укый.
- «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia) илкүләм чемпионатында икенче урын алган.
- Шәхси эшмәкәр булырга хыяллана.

:: Республикада уздырылган күп бәйгеләрдә даими катнашасың. Алар нинди мөмкинлекләр ача?

– Төрле бәйгеләрдә катнашу, көчемне сынап карау киләчәктә үземә файда китерер дип уйлыйм. Алар миңа күп мөмкинлекләр ача, киләчәккә юл сала. Әйтик, мине хәзер Казан дәүләт аграр университетына бушлай укырга чакыралар.

:: Алга таба нинди планнарың бар? Үзеңне киләчәктә кем итеп күрәсең?

– Алла боерса, көллиятне бетергәч, аграр университетына укырга керергә ниятем бар. Киләчәктә шәхси эшмәкәр буласым килә. Эшемне авыл хуҗалыгы, техника белән бәйләргә уйлыйм. Авыл хуҗалыгында хезмәт куярга, аны күтәреп, кирәкле итәргә телим.

Әңгәмәдәш – Ләйсән САФИНА

Кызыклы сәфәр

ТУКАЙ ЭЗЛӘРЕНӘ БАСЫП...

Көзге каникул алдыннан сыйныфыбыз белән Арча районының Кырлай һәм Кушлавыч авылларына юл тоттык. Сыйныф җитәкчебез Гөлшат Фәрхетдинова безгә татар теле һәм әдәбияты дәресләрен дә укыта. Аның бик тә укучыларын бөек шагыйребез Габдулла Тукай туган якларга алып барасы килде. Без исә бик теләп риза булдык.

Беренче тукталыш Кырлай авылында иде. Безне биредә күптән көтелгән кунак кебек каршы алдылар. Габдулла Тукай турында без бик күп мәгълүмат тупладык. Сәгъди бабай яшәгән йортка барып, анда элек кешеләрнең ничек яшәвен күрдек. Күңел белән шул елларга кайтып килдек. Күбебез авылга кайтып йөргәч, өй уртасында мич тә, морҗалар да, сандык, сәкеләр, самавыр, тастымаллар да безгә таныш иде. Шәһәрдә яшәүче сыйныфташларым өчен бу сәяхәт аеруча ошагандыр дип уйлыйм.

Без Кырлайда тәмле итеп ашадык та әле. Биредә эшләүче пешекчеләр бик тәмле пешерә икән. Авыл урамы буйлап та йөрдек. Кырлай авылында ике кибеткә кердек. Кешеләре ачык. Безнең татарча сөйләшүебезгә сокланып та калдылар әле. Кибетләре дә бик бай икән. Авыл кешесенең мул тормышта яшәвенә игътибар иттек. Авылда матур итеп төзелгән яңа йортлар да күп. Беләсезме, көз булса да, без Кырлайда әтәч-тавыкларга да юлыктык. Биредә бар да элеккечә дип кайттык. Кырлайда, чынлап та, тавыклары җырлай икән. Урам тутырып йөриләр. Бар матурлыкны күреп соклангач, Кушлавыч авылына кузгалдык. Биредә без Тукай турында тагын да күп яңалык ишеттек. Арчаны яратып кайтып киттек. Юлда да күңелле булды. Сыйныфташыбыз Адель юл буе гитара уйнап, без җырлап кайттык. Матур сәяхәтебез өчен укытучыбызга зур рәхмәт! Бу сәфәр безнең сыйныфны тагын да дуслаштырды.

Зилә ГЫЙЛЬМАНОВА,
Казан шәһәренең Абдулла Алиш исемендәге 20 нче гимназиясенең 9 нчы сыйныф укучысы

Киңәш-табыш

САК БУЛЫГЫЗ: ГРИПП!

ГРИППТАН НИЧЕК САКЛАНЫРГА?

- ✓ Авырган кешеләр янында булмаска.
- ✓ Өйне һәрдаим юып, җыештырып торырга.
- ✓ Бүлмәләрне җилләтергә.
- ✓ Пычрак куллар белән бит, борын, авыз, күзләрне тотмаска.
- ✓ Кулны һәрчак сабын белән юарга.
- ✓ Һава торышын исәпкә алып киенергә, туңмаска.
- ✓ Сәламәт яшәү рәвешен алып барырга (тиешенчә йокларга, саф һавада йөрергә, актив ял итәргә, витаминнарга бай ризыклар белән тукланырга).



! Тән температурасы 38-39°С булса, участок табибын яки ашыгыч ярдәм бригадасын чакыртыгыз. Авыруны аяк өсте кичерү бик куркыныч! Бу бик җитди өзлегүгә китерергә мөмкин.

АВЫРГАНДА НИШЛӘРГӘ?

- ✓ Кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә. Бары тик табиб кына диагноз куеп, дөрес дәвалау ысулын билгели ала.
- ✓ Өйдә калырга һәм күбрәк ятып торырга.
- ✓ Дәвалаучы табибның барлык киңәшләрен үтәргә.
- ✓ Даруларны вакытында эчәргә.
- ✓ Мөмкин кадәр күбрәк сыеклык эчәргә (кайнар чәй, нарат, мүк җиләге сыгынтылары).
- ✓ Йөткергәндә / төчкергәндә авыз-борынны кульяулык белән капларга кирәк.

Хикәя

Ярдәм

Урам уртасыннан карның каты кәзенә типкәләп барган Айрат үзенә дәшүләрен ишетеп туктап калды. Як-ягына карангалап торгач, ниһаять, агач янында басып торган сыйныфташы Рәзинәне күреп алды.

– Нәрсә кирәк? – диде ул, тавышын тамак төбеннән үк чыгарырга тырышып.

– Айрат, Айрат! Кил әле! Ярдәмең кирәк.

– Ни булды?

– Минә Йомшагым агач башына менеп китте дә төшә алмый. Нишләргә миңа хәзер?

Айрат югарыга, агач башына күтәрелеп карады. Чыннан да, анда аклы-каралы кечкенә генә песи баласы мияулап утыра иде. Өянкенең яше шактый, кәүсәләре бик юан, тотынып менәр өчен аскы өлешендә ботаклары да юк. Бары Айратның буе җитмәслек биеклектән генә икегә аерылып үсеп киткән. «Кызык, ничек шунда хәтле менә алды икән бу мәче баласы?» – дип уйлады ул эченнән генә.

Башын кашып бераз торгач, Айрат кар йомарлый башлады.

– Нишлисең син? – диде Рәзинә.

– Хәзер мәчеңне бәреп төшерәм. Борчылма, бер атуда тидерәм мин аңа!

– Атармын мин сиңа! Айрат, атма инде-е... Имгәтәсең бит Йомшагымны...

– Атам дигәч, атам!

– Айрат, агач башына үрмәләп кенә алып төш инде, зинһар!

– Юк! Бүген өй эшен күчертмәдең әле. Шуның аркасында тагын «икеле» алдым. Киттем мин...

– Айрат, тукта инде! Песиемне алып төшеп бирсәң, һәр көнне өй эшен күчертер идем. Йә инде, Айрат!

– Һмм... Күчертәм дисең, алайса?

– Әйе! Менәсеңме?

– Ярар! Кара аны, әгәр иртәгә алгебрадан дәфтәреңне бирмәсәң...

– Бирәм инде, бирәм!

Айрат, кулларын угалап, өянке янына килде, янә бер тапкыр агач башына карады. Ни гаҗәп: алар Рәзинә белән сөйләшкән арада песи баласыннан җилләр искән иде!

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН

Безгә язалар

Рәхәт очрашу

Һәр бала китап белән дус булырга тиеш. Шул максаттан без балалар бакчасында сабыйларны матур шигырьләр, әкиятләр белән таныштырабыз. Сабыйлар матур шигырьләрне тыңлап, аларны өйрәнеп үсәләр. Без әнә шулай итеп, телебезне саклауга өлеш кертәбез. Туган теле һәр балага кечкенәдән якын булырга, ул аны яратырга, үз телендә сөйләшергә тиеш.

Күптән түгел төбәгебез талантлары белән таныштыру максатыннан Түбән Кама шәһәренең 83 нче балалар бакчасында «Җылы сүз» дип аталган шигъри чара уздырдык. Бу юлы сабыйларны Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Илзирә Вәлиуллинаның иҗат юлы, китаплары белән таныштырдык. Чарада нәни укучыларыбыз өчен шагыйрәнең шигырьләре укылды.

Лилия ГАТАУЛЛИНА,
Түбән Кама шәһәренең 7 нче балалар китапханәчесе

Сәхифәне
Ләйсән САФИНА әзерләде

**Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 6692 данә
Гомуми тираж – 15344 данә**

Газетага сертификат бирелде Заказ 379

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+